ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02 июня 2023 ел № 4666

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 30 декабрендәге 476-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны файдалануга тапшыруга рөхсәт формасын раслау турында» 2002 елның 3 июнендәге 446/пр номерлы приказы, Шәһәр Уставы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын кушымтада каралганча расларга.

2. Башкарма комитетның «Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 31 маендагы 3680 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары А.С. Ганиевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 2 июнендәге
4666 номерлы карарына
кушымта

Төзелешкә рөхсәт бирү
буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты (алга таба – Регламент) төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт (алга таба – муниципаль хезмәт) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

1.2. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар: физик затлар, юридик затлар (алга таба – гариза бирүче).

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында мәгълүмат бирү

1.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат урнаштырыла:

1) дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр (алга таба – КФҮ) бүлмәләрендә урнашкан муниципаль хезмәт турында визуаль һәм текстлы мәгълүматны үз эченә алган мәгълүмат стендларында;

2) «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында (https://www. nabchelny.ru.) (алга таба – шәһәрнең рәсми сайты);

3) Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталында (https://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Республика порталы);

4) Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр (функцияләр) порталында (https://www.gosuslugi.ru/) (алга таба – Бердәм портал);

5) «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында (https://frgu.tatar.ru) (алга таба – Республика реестры).

1.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча консультация бирү гамәлгә ашырыла:

1) телдән мөрәҗәгать иткәндә КФҮдә – шәхсән яки телефон аша;

2) Республика порталының интерактив формасында;

3) Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетында (алга таба – Башкарма комитет):

телдән мөрәҗәгать иткәндә – шәхсән яки телефон аша;

язмача (шул исәптән электрон документ формасында) мөрәҗәгать иткәндә – кәгазьдә почта аша, электрон формада электрон почта аша.

1.3.3. Бердәм порталда, Республика порталында Республика реестрындагы мәгълүматлар нигезендә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат гариза бирүчегә бушлай бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүматтан файдалану, гариза бирүче тарафыннан нинди дә булса таләпләрне үтәмичә, шул исәптән аны гариза бирүченең техник чараларына урнаштыру түләү алу, теркәлү яки авторлаштыруны, яки аларга персональ мәгълүматлар бирүне күздә тотучы программа белән тәэмин итү хокукына ия зат белән лицензияле яки башка килешү төзүне таләп итә торган программа тәэминатыннан файдаланмыйча гамәлгә ашырыла.

1.3.4. Гариза бирүче шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать иткәндә, кергән мөрәҗәгать нигезендә, КФҮнең, Башкарма комитетның урнашу урыны (Татарстан Республикасы, Яр Чаллы шәһәре, Хәсән Туфан проспекты, 23 йорт, 249 кабинет, тел. 8(8552) 30-55-08, 30-58-14) турында; муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында, гаризалар бирү ысуллары һәм сроклары турында; муниципаль хезмәт күрсәтелә торган гражданнар категорияләре турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләрен җайга салучы норматив хокукый актлар турында; муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны карап тикшерү өчен кирәкле документлар исемлеге турында, гаризаны кабул итү һәм теркәү сроклары турында; муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында; муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча рәсми сайтта мәгълүмат урнаштыру урыны турында; Башкарма комитет вазыйфаи затларының гамәлләренә яки гамәл кылмавына шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелергә мөмкин.

Гариза бирүченең язма мөрәҗәгате буенча Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлегенең вазыйфаи затлары гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм Регламентның әлеге пунктында күрсәтелгән мәсьәләләрне язма рәвештә тулырак аңлаталар һәм, мөрәҗәгатьне теркәгәннән соң өч эш көне эчендә, гариза бирүчегә җавап җибәрәләр. Җаваплар мөрәҗәгать телендә бирелә. Мөрәҗәгать телендә җавап бирү мөмкин булмаган очракта, Татарстан Республикасының дәүләт телләре кулланыла.

1.3.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча мәгълүмат шәһәрнең рәсми сайтында һәм гариза бирүчеләр белән эшләү өчен Башкарма комитет бүлмәләрендәге мәгълүмат стендларында урнаштырыла.

Мәгълүмат стендларында һәм шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт телләрендәге мәгълүмат Регламентның 2.1, 2.3, 2.4, 2.5, 2.7, 2.9, 2.10, 2.11, 5.1 пунктларындагы муниципаль хезмәт турында мәгълүматны, Башкарма комитетның урнашу урыны, белешмә телефоннары, эш вакыты, муниципаль хезмәт күрсәтүгә гаризалар кабул итү графигы турында мәгълүматны үз эченә ала.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне җайга салучы норматив хокукый актлар исемлеге (норматив хокукый актлар реквизитларын һәм аларны рәсми бастырып чыгару чыганакларын күрсәтеп) шәһәрнең рәсми сайтында урнаштырылган.

Административ регламентның гамәлдәге редакциядәге тексты «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль районның рәсми сайтында, Республика реестрында урнаштырылырга тиеш.

1.5. Регламентта түбәндәге терминнар һәм билгеләмәләр файдаланыла:

гариза бирүче – муниципаль хезмәт күрсәтү турында телдән, язмача яки электрон формада запрос белән мөрәҗәгать иткән физик яки юридик затлар (дәүләт органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, дәүләт бюджеттан тыш фондлар органнарыннан һәм аларның территориаль органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан тыш) яисә аларның вәкаләтле вәкилләре;

төзүче – үзенә караган җир участогында капиталь төзелеш объектлары төзүне, реконструкцияләүне, шулай ук инженерлык тикшеренүләрен башкаруны, әлеге объектларны төзү, реконструкцияләү өчен проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы физик яки юридик зат;

техник заказчы – профессиональ нигездә эш итүче яки төзүче тарафыннан вәкаләтләнгән һәм төзүче исеменнән инженерлык тикшеренүләрен башкару турында, проект документларын әзерләү турында, капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү, капиталь ремонтлау турында шартнамәләр төзи, әлеге эш төрләрен башкаруга йөкләмәләр әзерли; инженерлык тикшеренүләрен башкаручы һәм (яки) проект документларын әзерләүне, капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне,

капиталь ремонтлауны гамәлгә ашыручы затларга күрсәтелгән эш төрләрен башкару өчен кирәкле материалларны һәм документларны тапшыра, проект документларын раслый, капиталь төзелеш объектын файдалануга тапшыруга рөхсәт алу өчен кирәкле документларны имзалый, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында (алга таба – РФ Шәһәр төзелеше кодексы) каралган башка функцияләрне гамәлгә ашыра торган юридик зат. Төзүче техник заказчы функцияләрен мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырырга хокуклы;

КФҮнең читтәге эш урыны – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге 1376 номерлы карары белән расланган Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләр эшчәнлеген оештыру кагыйдәләренең 34 пункты нигезендә Татарстан Республикасы муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында төзелгән КФҮнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офисы);

техник хата – муниципаль хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан җибәрелгән һәм документка (муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә) кертелгән мәгълүматларның бу мәгълүматларны кертүгә нигез булган документлардагы мәгълүматларга туры килмәвенә китергән хата (язудагы хата, басмадагы хата, грамматик яки арифметик хата яисә шуңа охшаш хата).

ЕСИА – электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада Бердәм идентификация һәм аутентификация системасы.

Федераль дәүләт мәгълүмат системасы – мәгълүмати хезмәттәшлектә катнашучыларның (гариза бирүче гражданнар һәм башкарма хакимият органнары һәм җирле үзидарә органнары вазыйфаи затларының) дәүләт мәгълүмат системаларында һәм башка мәгълүмат системаларында булган мәгълүматтан файдалану буенча санкцияләнгән мөмкинлеген тәэмин итә торган система;

КФҮ - «Татарстан Республикасында дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәк» дәүләт бюджет учреждениесе;

КФҮ АМС – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү буенча күпфункцияле үзәкләрнең автоматлаштырылган мәгълүмат системасы.

Регламентта муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гариза (алга таба – гариза) дигәндә «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) 2 статьясындагы 3 пункты нигезендә бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы запрос аңлашыла.

1.6. Төзелешкә рөхсәт капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты белән каралган бөтен срокка бирелә, мондый рөхсәт төзелеш, реконструкцияләүнең аерым этапларына бирелә торган очраклардан тыш.

1.7. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы төзүченең мондый рөхсәтнең гамәлдә булу срогы чыкканчыга кадәр кимендә 10 көн кала бирелгән гаризасы буенча озайтылырга мөмкин.

1.8. Төзелешкә рөхсәт бирү түбәндәге очракларда таләп ителми:

1) бакчачылык һәм яшелчәчелек өлкәсендәге законнар нигезендә билгеләнгән торак йортның, бакча йортының, хуҗалык корылмаларының бакча җире участогында эшмәкәрлек эшчәнлеген яки төзелешне, реконструкцияләүне гамәлгә ашыру белән бәйле булмаган максатлар өчен физик затка бирелгән җир участогында гараж төзү, реконструкцияләү;

2) индивидуаль торак төзелеше объектларын төзү, реконструкцияләү («Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә

катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә өлешләп төзүдә катнашучыларның акчаларын җәлеп итеп, индивидуаль торак төзелеше объектларын төзүдән тыш);

3) капиталь төзелеш объектлары булмаган объектларны төзү, реконструкцияләү;

4) аларга карау критерийлары Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә торган җир участогында ярдәмче файдалану төзелмәләре һәм корылмалары төзү;

5) капиталь төзелеш объектларын һәм (яки) аларның өлешләрен үзгәртү, әгәр мондый үзгәрешләр аларның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларына кагылмаса һәм рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкцияләүнең шәһәр төзелеше регламентында билгеләнгән чик параметрларыннан артмаса;

6) капиталь төзелеш объектларын капиталь ремонтлау, шул исәптән РФ Шәһәр Төзелеше кодексының 52 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очракта;

7) җир асты байлыклары турында Россия Федерациясе законнары нигезендә әзерләнгән, килештерелгән һәм расланган файдалы казылма ятмаларын эшкәртүнең техник проектында яки җир асты байлыклары участокларыннан файдалануга бәйле эшләрне башкару өчен башка проект документларында каралган бораулау скважиналарын төзү, реконструкцияләү;

8) чит илләрдә Россия Федерациясе илчелекләрен, консуллыкларын һәм вәкиллекләрен төзү, реконструкцияләү;

9) 1,2 мегапаскальгә кадәр басым астында табигый газны транспортлау өчен билгеләнгән объектларны төзү, реконструкцияләү;

10) элемтә чараларын урнаштыру өчен билгеләнгән 50 метрга кадәр биеклектәге антенна баганалары (мачта һәм башнялар) урнаштыру;

11) әгәр РФ Шәһәр төзелеше кодексы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең норматив хокукый актлары, Россия Федерациясе субъектларының шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында законнары нигезендә төзелеш өчен рөхсәт алу таләп ителмәсә, башка очракларда.

## 2. Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты

### 2.1. Муниципаль хезмәтнең исеме

Төзелешкә рөхсәт бирү

### 2.2. Турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче җирле үзидарә башкарма-боеру органының исеме

Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән – Башкарма комитетның архитектура, шәһәр төзелешен һәм торакны үстерү идарәсе (алга таба – АШТһТҮИ).

### 2.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең тасвирламасы

2.3.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып төзелешкә рөхсәт (2 нче кушымта) яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында белдерү кәгазе (3 нче кушымта) тора.

2.3.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе гариза бирүчегә «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы Федераль закон) нигезендә, Башкарма комитет вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында Республика порталының, Бердәм порталның шәхси кабинетына җибәрелә.

2.3.3. Гариза бирүченең теләге буенча, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе Башкарма комитет тарафыннан җибәрелгән электрон документның кәгазьдә бастырып чыгарылган һәм КФҮ мөһере, КФҮ хезмәткәренең имзасы белән расланган нөсхәсе формасында КФҮдә алынырга мөмкин.

2.3.4. Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ яки электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе формасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең гамәлдә булу срогы дәвамында алырга хокуклы.

2.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы, шул исәптән
муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешмаларга
мөрәҗәгать итү кирәклеген исәпкә алып, туктату мөмкинлеге
Россия Федерациясе законнарында каралган очракта,
муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату
срогы, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган
документларны бирү (җибәрү) срогы

2.4.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогы түбәндәгечә:

Төзелешкә рөхсәт бирү – гариза бирү көнен дә кертеп, биш эш көне. Муниципапаль хезмәт күрсәтү срогы гариза теркәлгән көннән исәпләнә башлый.

2.4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү срогын туктату каралмаган.

2.4.3. Гаризада күрсәтелгән элемтә ысулыннан файдаланып, электрон документ формасында муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документны җибәрү муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе рәсмиләштерелгән һәм теркәлгән көнне гамәлгә ашырыла.

2.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү, шулай ук муниципаль
хезмәтләр күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр
күрсәтү өчен законнар һәм башка норматив-хокукый актлар нигезендә
кирәкле һәм гариза бирүче тапшырырга тиешле документларның
тулы исемлеге, гариза бирүче тарафыннан аларны кабул итү ысуллары,
шул исәптән электрон формада,
аларны тапшыру тәртибе

2.5.1. Капиталь төзелеш объекын төзгән, реконструкцияләгән очракта, гариза бирүче тапшыра:

1) гариза (1 нче кушымта):

- кәгазь документ формасында;

- Региональ портал, Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган электрон формада;

2) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 15 өлеше нигезендә расланган проект документларындагы түбәндәге материаллар:

а) аңлатма язуы;

б) җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыру схемасы, ә проект документларын линия

объектларына карата әзерләгән очракта территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган күчерү полосасы проекты (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш);

в) архитектура һәм конструктив карарлар булган бүлекләр, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына кагылышлы проект документларын әзерләгән очракта);

г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен кирәк булган очракта капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү буенча эшләрне оештыру проектын да кертеп);

3) аның нигезендә капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, шул исәптән әлеге проект документларында, линия объектларын да кертеп, башка капиталь төзелеш объектларын төзү яки реконструкцияләү каралган очракта (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 12.1 өлешендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата), проект документларына экспертизаның уңай нәтиҗәсе (проект документлары РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү өлешендә), әгәр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә мондый проект документларына экспертиза үткәрелергә тиеш булса, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе;

4) мондый объектны реконструкцияләгән очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, күпфатирлы йортны реконструкцияләүнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7 өлешнең 6.2 пунктында күрсәтелгән очракларыннан тыш, блоклы төзелеш йортларының берсен реконструкцияләгән очракта, бер рәттә блоклы төзелештәге барлык йортларның хокук ияләренең ризалыгы;

5) реконструкцияләү дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы) булып торучы дәүләт (муниципаль) заказчысы, «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фонд белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан хокук иясе булган, аңа карата күрсәтелгән орган гамәлгә куючы фунуцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган, дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, дәүләт (муниципаль) бюджет яки автономияле учреждение булган дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектында үткәрелгән очракта - мондый реконструкцияләү үткәрүгә, шул исәптән реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртибен билгеле торган килешү;

6) күпфатирлы йортта биналарның һәм машина-урыннарның милекчеләренең гомуми җыелышы карары, ул күпфатирлы йортны реконструкцияләгән очракта торак законнары нигезендә кабул ителә, яки мондый реконструкция нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми милек күләме кимегән очракта, күпфатирлы йорттагы биналарның һәм машина-урыннарының барлык милекчеләренең ризалыгы;

7) мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкарганда мондый объектның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларна кагылган очракта, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар.

8) аны урнаштыру сәбәпле, Россия Федерациясе законнары нигезендә территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле капиталь төзелеш объектын төзегән очракта яки аның нәтиҗәсендә реконструкцияләгән объектка карата территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә яки элек билгеләнгән территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона үзгәрергә тиешле капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгән очракта, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карар күчермәсе (2025 елның 1 гыйнварыннан соң бирелә).

2.5.2. Әгәр 2.5.1 пунктының 3, 5, 7 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында яки бердәм дәүләт бәяләмәләр реестрында булмаса, күрсәтелгән документлар гариза бирүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә җибәрелә.

2.5.3. Рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайтканда гариза бирүче тапшыра:

1) төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайту турында гариза (төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы чыкканчыга кадәр кимендә 10 календарь көн кала тапшырыла);

2) төзелешкә рөхсәтнең төп нөсхәсе.

Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайту турында гариза өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе нигезендә торак урынын, күпфатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өчен гражданнар һәм юридик затларның акчаларын җәлеп иткән гариза төзүче тарафыннан бирелгән очракта, мондый гаризага төзүче тарафыннан өлешләп төзүдә катнашу шартнамәсе буенча торак урынын тапшыру буенча йөкләмәләрне тиешенчә үтәве өчен банкның поручительлек килешүе яки күпфатирлы йортны һәм (яки) башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзү өчен акча җәлеп итүче затның (төзүче) гражданлык җаваплылыгын иминләштерү шартнамәсе беркетелергә тиеш.

2.5.4. Җир участогына хокуклар күчү сәбәпле үзгәрешләр кертү турында гариза биргәндә, гариза бирүче түбәндәгеләрне тапшыра:

а) Регламентның 5 нче кушымтасында каралган форма буенча, җир участогына хокуклар күчү турында белдерү кәгазе;

б) җир участогына хокуклар күчү турында белдерү кәгазе бирелгән очракта, гариза бирүченең яки гариза бирүче вәкиленең шәхесен раслаучы документ;

в) гариза бирүче вәкиленең гариза бирүче исеменнән эш итү вәкаләтләрен раслаучы документ (хезмәт күрсәтүне сорап гариза бирүченең вәкиле мөрәҗәгать иткән очракта);

г) төзелешкә рөхсәтнең төп нөсхәсе.

2.5.5. Гариза һәм теркәлә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсе белән тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) турыдан-туры төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органына;

2) КФҮ һәм төзелешкә рөхсәт бирүгә вәкаләтле җирле үзидарә органы арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү нигезендә, КФҮ аша;

3) Бердәм порталдан файдаланып, шулай ук Республика порталы аша электрон формада;

4) шәһәр төзелеше эшчәнлеге өлкәсендә вәкаләтләрне гамәлгә ашыруга автоматлаштырылган мәгълүмати-аналитик ярдәм функцияләре булган шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча дәүләт мәгълүмат системаларыннан файдаланып;

5) «Күпфатирлы йортларны һәм башка күчемсез милек объектларын өлешләп төзүдә катнашу турында һәм Россия Федерациясенең кайбер закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2004 елның 30 декабрендәге 214-ФЗ номерлы Федераль законда каралган торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасыннан файдаланып, Россия Федерациясе

Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 7.4 өлешендәге 1-4 пунктларында күрсәтелгән ысуллар белән беррәттән, исемнәре «махсуслаштырылган төзүче» сүзләрен үз эченә алган төзүчеләр өчен, Россия Федерациясе субъектының норматив хокукый акты нигезендә, төзелешкә рөхсәт бирү турында гариза бирү торак төзелешенең бердәм мәгълүмат системасы белән интеграцияләнергә тиешле башка мәгълүмат системалары аша башкарылган очраклардан тыш.

2.5.6. Физик затлар һәм шәхси эшмәкәрләр гаризаны һәм кирәкле документларны Республика порталы аша җибәргәндә, гаризаны гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имза алу өчен гариза бирүчегә ЕСИАда теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алу язмасын стандарттан ким булмаган дәрәҗәгә кадәр расларга кирәк.

Запросны Республика порталы аша биргәндә гариза бирүче 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә, мондый документларны булдыруга һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган документларның электрон рәвешләрен яисә электрон формадагы документларны тапшыра.

2.5.7. Гариза бирүчедән таләп итү тыела:

1) муниципаль хезмәт күрсәтүгә бәйле барлыкка килә торган мөнәсәбәтләрне җайга сала торган норматив хокукый актларда тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар һәм мәгълүмат тапшыруны яки эшләрне гамәлгә ашыруны;

2) муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле һәм башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына, оешмаларга мөрәҗәгать итүгә бәйле гамәлләрне, шул исәптән килешүләрне гамәлгә ашыру, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән исемлеккә кертелгән хезмәтләрдән файдаланудан һәм мондый хезмәтләр (кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр) күрсәтү нәтиҗәсендә бирелә торган документларны һәм мәгълүматны алудан тыш;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документлар яки мәгълүмат тапшыруны, түбәндәге очраклардан тыш:

а) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризаны беренче тапкыр биргәннән соң, муниципаль хезмәт күрсәтүгә кагылышлы норматив хокукый актларның таләпләре үзгәрү;

б) муниципаль хезмәт күрсәтү турында гаризада һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң гариза бирүче тарафыннан тапшырылган һәм элек бирелгән документлар комплектына кертелмәгән документларда хаталар булу;

в) документларның гамәлдә булу срогы тәмамлану яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканнан соң мәгълүмат үзгәрү;

г) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтүдән беренче тапкыр баш тартканда, Башкарма комитет вазыйфаи затының, КФҮ хезмәткәренең хаталы яки хокукка каршы гамәленең (гамәл кылмавының) докуметлар белән расланган факты (билгеләре) ачыклану, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда, бу хакта Башкарма комитет Җитәкчесе имзасы белән язма рәвештә гариза бирүчегә хәбәр ителә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә;

4) 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 7.2 пункты нигезендә элек электрон рәвешләре танықланган документларны һәм мәгълүматны кәгазьдә бирү, мондый документларга тамгалар кую яисә аларны алу дәүләт һәм

муниципаль хезмәт күрсәтүнең кирәкле шарты булып торган очраклардан һәм федераль законнарда билгеләнгән башка очраклардан тыш.

2.6. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен норматив хокукый актлар нигезендә кирәкле, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалар карамагындагы һәм гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларның тулы исемлеге, шулай ук гариза бирүче тарафыннан аларны алу ысуллары, шул исәптән электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар алар карамагында булган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма

2.6.1. Индивидуаль торак төзелеше объектлары булмаган объектлар төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта түбәндәге документлар (мәгълүматлар) сорала:

1) җир участогына хокук билгеләүче документлар, шул исәптән сервитут билгеләү турында килешү, җәмәгать сервитуты билгеләү турында карар, шулай ук РФ Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 статьясының 1.1 өлешендә каралган очракта, аның нигезендә күрсәтелгән җир участогы барлыкка килгән һәм җир участогының шәһәр төзелеше планы бирелгән территориянең кадастр планында җир участогы яки җир участоклары урнашу схемасы, әгәр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 7.3 өлешендә башкача билгеләнмәгән булса;

Әгәр федераль әһәмияткә ия объектны, региональ әһәмияткә ия объектны яки җирле әһәмияткә ия объектны төзү, реконструкцияләү өчен җир участогы яки җир участоклары дәүләт яисә муниципаль милектәге җирләрдән һәм (яки) җир участокларыннан, мондый җирләр һәм (яки) җир участоклары өченче затларның хокуклары (сервитут, җәмәгать сервитуты) белән чикләнмәгән булу шарты белән, дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдән һәм (яки) җир участокларыннан барлыкка килгән очракта (җир законнарында каралган нигезләр буенча территорияне планлаштыруның расланган проекты нигезендә дәүләт ихтыяҗлары өчен алынырга тиешле җирләрдән тыш), мондый объектны төзүгә рөхсәт бирү территорияне межалауның расланган проекты һәм, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 57.3 статьясының 1.1 өлешенә туры китереп бирелгән җир участогының шәһәр төзелеше планы һәм территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының җир законнары нигезендә расланган урнашу схемасы нигезендә, җир законнарына туры китереп, күрсәтелгән җир участогы яки җир участоклары булдырылганчы рөхсәт ителә. Бу очракта, капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү өчен, җир участогына хокук билгеләүче документлар бирү таләп ителми. Әлеге хокук билгеләүче документлар урынына, төзелешкә рөхсәт бирү турындагы гаризага территорияне межалауның расланган проекты реквизитлары яисә территориянең кадастр планында җир участогының яки җир участокларының урнашу схемасы теркәлә. Аларны төзү, реконструкцияләү җир законнарында каралган нигезләр буенча, территорияне межалауның расланган проектына туры китереп, шул исәптән дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен алынырга тиешле җир участкларында гамәлгә ашырыла торган федераль әһәмияткә ия объектны, региональ әһәмияткә ия объектны яки җирле әһәмияткә ия объектны төзүгә рөхсәт бирелгән очракта, дәүләт яки муниципаль ихтыяҗлар өчен аларны алу сәбәпле, өченче затларның мондый җир участокларына хокуклары җир законнарында билгеләнгән тәртиптә туктатылганчы, күрсәтелгән төзелеш, реконструкция рөхсәт ителми.

2) Россия Федерациясе бюджет законнарында, дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы), «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фонды белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан билгеләнгән очракларда бюджет инвестицияләрен гамәлгә ашырганда төзелгән дәүләт (муниципаль) заказчысының вәкаләтләрен тапшыру турында килешү булганда – күрсәтелгән килешү, әлеге килешүне төзегән хокук иясенең җир участогына хокук билгеләүче документлары;

3) төзелешкә рөхсәт алу өчен гариза биргән көнгә кадәр өч елдан да иртәрәк бирелмәгән участокның шәһәр төзелеше планы яки линия объектын төзүгә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты реквизитлары (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш), урнаштыру өчен җир участогы булдыру таләп ителмәгән линия объектын төзүгә рөхсәт бирелгән очракта территорияне планлаштыру проектының реквизитлары;

4) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 15 өлеше нигезендә расланган проект документларындагы түбәндәге материаллар:

а) аңлатма язуы;

б) җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыру схемасы, ә проект документларын линия объектларына карата әзерләгән очракта, территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган күчерү полосасы проекты (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш);

в) архитектура һәм конструктив карарлар булган бүлекләр, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына кагылышлы проект документларын әзерләгән очракта);

г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен кирәк булган очракта капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү буенча эшләрне оештыру проектын да кертеп);

5) аның нигезендә капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү, шул исәптән әлеге проект документларында, линия объектларын да кертеп, башка капиталь төзелеш объектларын төзү яки реконструкцияләү каралган очракта (РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 12.1 өлешендә каралган очракта, төзелешнең аерым этапларына карата), проект документ документларына экспертизаның уңай нәтиҗәсе (проект документлары РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 5 өлешендәге 1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килү өлешендә), әгәр РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы нигезендә мондый проект документларына экспертиза үткәрелергә тиеш булса, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 3.4 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 6 өлешендә каралган очракларда проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе;

6) проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар әгъзалыгына нигезләнгән үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасы булган зат тарафыннан бирелгән һәм әлеге зат тарафыннан әлеге Кодекс нигезендә проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектын оештыру буенча җәлеп ителгән белгеч тарафыннан

расланган проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау кәгазе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта;

7) башкарма хакимият органы яки проект документларына экспертиза үткәргән оешма тарафыннан проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау кәгазе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлеше нигезендә эксперт барышында проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта;

8) рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан чыгуга рөхсәт (төзүчегә мондый рөхсәт РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 40 статьясы нигезендә бирелгән очракта);

9) проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертиза бәяләмәсе бирелгән очракта, проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертиза һәм (яки) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә дәүләтнеке булмаган экспертиза үткәрү хокукына аккредитацияләнгән юридик затларның дәүләт реестрында проект документларына дәүләтнеке булмаган экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән юридик затның аккредитациясе турында уникаль язма номеры;

10) аны урнаштыру сәбәпле, Россия Федерациясе законнары нигезендә территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле капиталь төзелеш объектын төзегән очракта яки аның нәтиҗәсендә реконструкцияләгән объектка карата территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә яки элек билгеләнгән территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона үзгәрергә тиешле капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгән очракта, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карар (2025 елның 1 гыйнварыннан башлап бирелә. бирелә. Әлеге пункт «Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 3 августындагы 342-ФЗ номерлы Федераль законның 26 статьясының 18 өлешендә билгеләнгән очракта кулланылмый);

11) капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне җирле үзидарә органы тарафыннан территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта территорияне үстерү турында шартнамә күчермәсе (территорияне комплекслы үстерү турында карар Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек тарафыннан мөстәкыйль тормышка ашырылган яки яисә мондый карар РФ Шәһәр төзелеше нигезендә билгеләнгән юридик зат яки Россия Федерациясе субъекты тарафыннан тормышка ашырылган очраклардан тыш).

2.6.2. Әгәр 2.6.1 пунктының 1, 4, 5 пунктчаларында күрсәтелгән документлар (аларның күчермәләре яки аларда булган мәгълүматлар) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында яки бердәм дәүләт бәяләмәләр реестрында булмаса, күрсәтелгән документлар гариза бирүче тарафыннан мөстәкыйль рәвештә җибәрелә.

2.6.3. Гариза бирүчедән дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагында булган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүче тарафыннан түләү кертүне раслаучы документлар таләп итү тыела.

Гариза бирүче тарафыннан дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм дәүләт органнары яки җирле үзидарә органнары карамагында булган мәгълүматларны үз эченә алган документларны тапшырмау гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тормый.

## 2.7. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.7.1. Документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) гаризада һәм гаризага теркәлә торган документларда килешенмәгән төзәтүләр, аларның эчтәлеген бертөрле генә аңларга мөмкинлек бирми торган җитди кимчелекләр булу;

2) документларны тиешле булмаган органга тапшыру;

3) үз көчен югалткан документларны тапшыру;

4) гариза бирүче исеменнән гариза (запрос) аңа вәкаләтле булмаган зат тарафыннан бирелү;

5) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен, Регламент нигезендә муниципаль хезмәттән файдаланучы булып тормаган зат мөрәҗәгать итү;

6) гаризаның электрон формасында мәҗбүри кырларны дөрес тутырмау;

7) гаризаның электрон формасында һәм тапшырылган документларда каршылыклы мәгълүматлар булу;

8) электрон формадагы гариза (запрос) һәм башка документлар, гамәлдәге законнарны бозып, электрон имзадан файдаланып имзаланган;

9) электрон документлар аларны бирү форматларына карата таләпләргә туры килми һәм (яки) укылмый.

2.7.2. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге тулы булып тора.

2.7.3. Гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар гариза бирүчене кабул итү вакытында да, гаризаны теркәгән көнне дә кертеп биш эш көненнән артмаган срокта, АШТһТҮИ шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлегенең җаваплы вазыйфаи заты тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлектән файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) алганнан соң да кабул ителергә мөмкин.

2.7.4. Муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турындагы карар, баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана һәм Республика порталының, Бердәм порталның шәхси кабинетына гариза бирүчегә һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне КФҮгә җибәрелә.

2.7.5. Гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар, Бердәм порталда бастырып чыгарылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә тапшырылган очракта, гаризаны һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

## 2.8. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату яки баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.1. Законда муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату өчен нигезләр каралмаган.

2.8.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

1) гариза бирүче тарафыннан Регламентның 2.5 пунктында каралган документлар тулы күләмдә тапшырылмаган, яисә тапшырылган гаризада һәм (яки) документларда тулы булмаган һәм (яки) дөрес булмаган мәгълүмат бар;

2) тапшырылган документларның, төзелешкә рөхсәт алу өчен бирелгән җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән, капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата таләпләргә туры килмәве;

3) әгәр тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаган булса, дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының яисә дәүләт хакимияте органына яисә җирле үзидарә органына караган оешманың муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яисә) мәгълүмат булмауны таныклаучы ведомствоара запроска җавабы керү, тиешле документ гариза бирүче тарафыннан үз инициативасы белән тапшырылмаган булса;

4) линия объектын төзүгә рөхсәт бирелгән очракта, тапшырылган документларның территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителмәгән очраклардан тыш), шулай ук җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм төзелешкә, таләпләргә рөхсәт бирү датасына гамәлдә булган чикләүләргә, рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килмәве;

5) мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтләнгән Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимият органыннан капиталь төзелеш объектының проект документлары бүлегенең тарихи җирлекне саклау предметына һәм капиталь төзелеш объектларының шәһәр төзелеше регламенты тарафыннан федераль яки региональ әһәмияттәге тарихи җирлек территориясендә урнашкан территориаль зонага карата билгеләнгән архитектура карарлары таләпләренә туры килмәве турында бәяләмә килү, әгәр ул линия объекты булып тормаса һәм аны төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияткә ия тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү турында гариза бирелгән булса;

6) әгәр капиталь төзелеш объектын төзү, реконструкцияләү җирле үзидарә органы тарафыннан җирле үзидарә органы инициативасы буенча территорияләрне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территориядә планлаштырылса, территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә нигезендә расланган территорияне планлаштыру буенча документлар булмау. Территорияне комплекслы үстерү турында карар Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек тарафыннан мөстәкыйль тормышка ашырылу яки мондый карар РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә билгеләнгән юридик зат яки Россия Федерациясе субъекты тарафыннан тормышка ашырылу искәрмә булып тора.

2.8.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге тулы булып тора.

2.8.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп баш тарту турындагы карар Регламентка 3 нче кушымтада билгеләнгән форма нигезендә рәсмиләштерелә, көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан имзалана һәм гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар кабул ителгән көнне Республика порталының шәхси кабинетына һәм (яки) КФҮгә җибәрелә.

2.8.5. Муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза Бердәм порталда бастырылган муниципаль хезмәт күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту тыела.

### 2.8.6. Җир участогына хокуклар күчү, берләштерү, бүлү, яңадан бүлү, аерып бирү юлы белән җир участогы булдыруга бәйле рәвештә төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.8.6.1 Гариза бирүче тарафыннан РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә аларга яки аларның берсенә карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир участокларын берләштерү юлы белән җир участогы булдыру турында белдерү кәгазе биргәндә, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

а) җир законнары нигезендә дәүләт хакимияте башкарма органы яки җирле үзидарә органы җир участогы булдыру турында карар кабул иткән очракта, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә аларга яки аларның берсенә карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир участокларын берләштерү юлы белән җир участогы булдыру турында белдерү кәгазендә җир участогы булдыру турында карар реквизитлары булмау;

б) аларга яки аларның берсенә РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелешкә рөхсәт бирелгән җир участокларын берләштерү юлы белән җир участогы булдыру турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән мәгълүматлар дөрес булмау;

в) төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланганчы 10 эш көненнән ким вакыт эчендә бирелү.

2.8.6.2. Гариза бирүче тарафыннан РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә аларга яки аларның берсенә карата төзелешкә рөхсәт бирелгән җир участокларын бүлү, яңадан бүлү яки җир участокларыннан аерып бирү юлы белән җир участогы булдыру турында белдерү кәгазе биргәндә, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән түбәндәге очракларда баш тартыла:

а) җир законнары нигезендә дәүләт хакимияте башкарма органы яки җирле үзидарә органы җир участогы булдыру турында карар кабул иткән очракта, җир участокларын бүлү, яңадан бүлү яки җир участокларыннан аерып бирү юлы белән җир участогы булдыру турында белдерү кәгазендә җир участогы булдыру турында карар реквизитлары булмау;

б) аларга карата РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелешкә рөхсәт бирелгән җир участокларын бүлү, яңадан бүлү яки җир участокларыннан аерып бирү юлы белән җир участогы булдыру турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән мәгълүматлар дөрес булмау;

в) планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын урнаштыру, аларга карата РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелешкә рөхсәт бирелгән җир участокларын бүлү, яңадан бүлү яки җир участокларыннан аерып бирү юлы белән булдырылган җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата таләпләргә туры килмәү;

г) аларга карата РФ Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелешкә рөхсәт бирелгән җир участокларын бүлү, яңадан бүлү яки җир участокларыннан аерып бирү юлы белән булдырылган җир участогының тапшырылган шәһәр төзелеше планы җир участокларын бүлү, яңадан бүлү яки җир участокларыннан аерып бирү юлы белән җир участогы булдыру турында белдерү кәгазе җибәрелгән көнгә кадәр өч ел алдан бирелгән;

д) аларга карата Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелешкә рөхсәт бирелгән җир участокларын бүлү, яңадан бүлү яки җир участокларыннан аерып бирү юлы белән җир участоклары булдырылган очракта, планлаштырыла торган капиталь төзелеш объекты җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалануга һәм (яки) Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән һәм төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында карар кабул итү датасына

гамәлдә булган чикләүләргә туры килмәү;

е) төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланганчы 10 эш көненнән ким вакыт эчендә бирелү.

2.8.6.3. Гариза бирүче тарафыннан җир участогына хокуклар күчү турында белдерү кәгазе бирелгәндә, түбәндәге очракларда төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарта:

а) җир участогына хокуклар күчү турында белдерү кәгазендә мондый җир участогына хокук билгеләүче документларның реквизитлары булмау;

б) Бердәм дәүләт күчемсез милек реестрында җир участогына хокук билгеләүче документлар турында мәгълүматлар булмаган очракта, җир участогына хокук билгеләүче документлар булмау;

в) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә төзелешкә рөхсәт бирелгән җир участогына хокуклар күчү турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән мәгълүматлар дөрес булмау;

г) төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланганчы 10 эш көненнән ким вакыт эчендә бирелү.

2.9. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен алына торган дәүләт пошлинасын яки башка түләүне алу тәртибе, күләме һәм нигезләре

Муниципаль хезмәт түләүсез нигездә күрсәтелә

2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр исемлеге, шул исәптән муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан бирелә торган документ (документлар) турында мәгълүматлар

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.11. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган хезмәтләр күрсәтүгә түләү алу тәртибе, күләме һәм нигезләре, мондый түләү күләмен исәпләү методикасы турында мәгълүматны да кертеп

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

2.12. Муниципаль хезмәт, муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында запрос биргәндә һәм мондый хезмәтләрне күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы

2.12.1. Муниципаль хезмәттән файдалануга гариза биргәндә көтү вакыты – 15 минуттан артык түгел.

2.12.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь срогы 15 минуттан артырга тиеш түгел.

2.13. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы оешма тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтне күрсәтү турында запросын теркәү срогы һәм тәртибе, шул исәптән электрон формада

2.13.1. Гариза биргән көнне КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ АМСтан гариза бирүчегә гаризаның җибәрелүен раслаучы, теркәү номеры һәм электрон гариза бирү датасы куелган расписка бирелә.

2.13.2. Гаризаны Республика порталы, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы аша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Республика порталының, Бердәм дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталының шәхси кабинетында һәм электрон почта аша, теркәү номеры һәм гариза бирү датасы күрсәтелгән, гариза җибәрелүне раслаучы белдерү кәгазе ала.

## 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтелә торган биналарга, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләре һәм һәр муниципаль хезмәтне күрсәтү өчен кирәкле документлар исемлеге булган мәгълүмат стендларына, мондый хезмәтне күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат урнаштыруга һәм рәсмиләштерүгә, шул исәптән инвалидларны социаль яклау турында федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә, күрсәтелгән объектларның инвалидлар өчен уңайлылыгын тәэмин итүгә таләпләр

2.14.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм бүлмәләрдә гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документлар рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырыла.

Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү мөмкинлеге тәэмин ителә (бинага уңайлы керү-чыгу һәм алар чикләрендә хәрәкәт итү).

Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турындагы визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүмат гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен истә тотып урнаштырыла.

2.14.2. Инвалидларны социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керү максатларында тәэмин ителә:

1) күрү һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга ярдәм күрсәтү;

2) транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү, шул исәптән кресло-коляскадан файдаланып;

3) аларның яшәеш мөмкинлекләре чикле булуны исәпкә алып, инвалидларның хезмәтләрдән тоткарлыксыз файдалануын тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөрткечләрне тиешенчә урнаштыру;

4) ишетә һәм күрә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны рельефлы-нокталы Брайль шрифтында башкарылган билгеләр белән кабатлау;

5) сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемәчене кертү;

6) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының «Юл күрсәтүче этне махсус өйрәтүне раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» 2015 елның 22 июнендәге 386н Боерыгы белән билгеләнгән форма буенча һәм тәртиптә бирелә һәм махсус өйрәтелгән булуын раслый торган документы булганда, юл күрсәтүче этне кертү;

2.14.3. Инвалидлар өчен муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларга керү һәм әлеге пунктның 1-4 пунктчаларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдә кулланыла торган чаралардан файдалануны тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яки модернизацияләнгән, реконструкцияләнгән объектларга һәм чараларга карата кулланыла.

## 2.15. Муниципаль хезмәтнең һәркем файдалана алырлык булу һәм сыйфат күрсәткечләре, шул исәптән гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәткәндә вазыйфаи затлар белән үзара эшчәнлеге саны һәм аларның дәвамлылыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат алу мөмкинлеге, шул исәптән мәгълүмат-коммуникация технологияләренән файдаланып, КФҮдә (шул исәптән тулы күләмдә), гариза бирүченең сайлавы буенча (экстерриториаль принцип), җирле үзидарә органы башкарма-боеру органының теләсә кайсы территориаль бүлекчәсендә, КФҮдә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында каралган берничә дәүләт һәм (яки) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос (комплекслы запрос) ярдәмендә муниципаль хезмәттән файдалану мөмкинлеге яисә мөмкин булмау

2.15.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булу күрсәткечләре булып тора:

документларны кабул итү һәм бирү башкарыла торган бинаның җәмәгать транспортыннан һәркем файдалана алырлык зонада урнашуы;

кирәкле сандагы белгечләр, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итүне гамәлгә ашыра торган бүлмәләр булу;

мәгълүмат стендларында, муниципаль районның рәсми сайтында, Бердәм порталда, Республика порталында муниципаль хезмәт күрсәтү ысуллары, тәртибе һәм сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

инвалидларга хезмәтләрдән башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә файдалануга комачаулый торган каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.

2.15.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләре булып тора:

1) документларны кабул итү һәм карап тикшерү срокларын үтәү;

2) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу срогын үтәү;

3) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга нигезле шикаятьләр булмау;

4) гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән үзара хезмәттәшлеге саны (консультацияләрне исәпкә алмыйча):

4.1) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүченең КФҮ хезмәткәрләре белән хезмәттәшлеге барлык кирәкле документлар белән гариза биргәндә бер тапкыр гамәлгә ашырыла;

4.2) КФҮдә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документның кәгазь нөсхәсе формасында алу кирәк булган очракта бер тапкыр.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә, гариза бирүченең вазыйфаи затлар белән бер хезмәттәшлек дәвамлылыгы 15 минуттан артмый.

Гариза бирүче күчмә радиотелефон элемтәсе җайланмалары ярдәмендә, Бердәм порталдан, Республика порталыннан, терминал җайланмаларыннан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләргә хокуклы.

2.15.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышы турында мәгълүмат гариза бирүче тарафыннан Бердәм порталда яки Республика порталында, КФҮдә алынырга мөмкин.

2.15.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү экстерриториаль принцип буенча, яшәү урынына яки фактта яшәү (тору) урынына бәйсез рәвештә, гариза бирүченең сайлавы буенча теләсә кайсы КФҮдә гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт комплекслы запрос составында күрсәтелә.

## 2.16. Башка, шул исәптән экстерриториаль принцип буенча муниципаль хезмәт күрсәтү үзенчәлекләрен (әгәр муниципаль хезмәт экстерриториаль принцип буенча күрсәтелсә) һәм муниципаль хезмәтне электрон формада күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә алучы таләпләр

2.16.1. Муниципаль хезмәт электрон формада күрсәтелгәндә гариза бирүче хокуклы:

а) Бердәм порталда яки Республика порталында урнаштырылган муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында мәгълүмат алырга;

б) Республика порталыннан, Бердәм порталдан файдаланып, муниципаль хезмәт күрсәтү турында гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 1 өлешнең 7.2 пункты нигезендә элек электрон рәвешләре таныкланган документларны һәм мәгълүматны бирергә;

в) электрон формада бирелгән муниципаль хезмәт күрсәтү турындагы гаризаларны үтәү барышы турында мәгълүматлар алырга;

г) Республика порталы аша муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

д) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ формасында алырга;

е) Башкарма комитетның, шулай ук аның вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең карарына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына), Республика порталы, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәткәндә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче органнар, аларның вазыйфаи затлары, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан башкарылган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы аша шикаять бирергә.

2.16.2. Гаризаны формалаштыру, гаризаны нинди дә булса башка формада өстәмә рәвештә бирмичә, Бердәм порталда, Республика порталында гаризаның электрон формасын тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

2.16.3. Гариза бирүчеләрнең кабул итүгә язылуы (алга таба – язылу) Республика порталы, Бердәм портал, КФҮнең контакт-үзәге телефоны аша гамәлгә ашырыла.

Гариза бирүчегә, КФҮдә билгеләнгән кабул итү графигы чикләрендә, кабул итү өчен теләсә кайсы буш датага һәм вакытка язылу мөмкинлеге бирелә.

Билгеле бер датага язылу әлеге датага кадәр бер тәүлек алдан тәмамлана.

Республика порталы, Бердәм портал аша алдан язылуны гамәлгә ашыру өчен, гариза бирүчегә системада сорала торган мәгълүматларны күрсәтергә кирәк, шул исәптән:

фамилиясе, исеме, атасының исеме (булганда);

телефон номеры;

электрон почта адресы (теләге буенча);

кабул итүне теләгән көн һәм вакыт.

Алдан язылу вакытында гариза бирүче хәбәр иткән мәгълүматлар шәхси кабул итү вакытында гариза бирүче тарафыннан бирелгән документларга туры килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарыла.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда, гариза бирүчегә раслау талоны чыгартып алу мөмкинлеге бирелә. Гариза бирүче электрон почта адресын хәбәр иткән очракта, күрсәтелгән адреска шулай ук кабул итү датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, алдан язылуны раслау турында мәгълүмат җибәрелә.

Алдан язылуны гамәлгә ашырганда гариза бирүчегә, кабул итүнең билгеләнгән вакытыннан 15 минут узгач, ул килмәгән очракта, алдан язылу гамәлдән чыгарылу турында мәҗбүри рәвештә хәбәр ителә.

Гариза бирүче теләсә кайсы вакытта алдан язылудан баш тартырга хокуклы. Гариза бирүчедән, Россия Федерациясенең норматив хокукый актлары нигезендә идентификация һәм аутентификация узудан, кабул итү максатын күрсәтүдән, шулай ук кабул итү өчен броньларга кирәк булган вакыт интервалы дәвамлылыгын исәпләү өчен кирәкле мәгълүматлардан тыш, башка гамәлләр башкаруны таләп итү тыела.

## 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм үтәү сроклары, аларны үтәү тәртибенә таләпләр, шул исәптән административ процедураларны электрон формада үтәү үзенчәлекләре, шулай ук административ процедураларны КФҮдә үтәү үзенчәлекләре

### 3.1. Муниципаль хезмәт күрсәткәндә гамәлләр эзлеклелеген тасвирлау

3.1.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү түбәндәге процедураларны үз эченә ала:

1) гариза бирүчегә консультацияләр бирү;

2) гариза бирүче тарафыннан бирелгән документлар комплектын кабул итү һәм карап тикшерү;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар җибәрү;

4) муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү;

5) гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү);

6) техник хаталарны төзәтү.

### 3.2. Гариза бирүчегә консультацияләр бирү

3.2.1. Гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтү белән бәйле мәсьәләләр буенча мөрәҗәгате административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып тора:

- гариза бирүче КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә – КФҮ хезмәткәре;

- гариза бирүче Башкарма комитетка мөрәҗәгать иткәндә АШТһТҮИ шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге белгече (алга таба – консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат).

3.2.2. Гариза бирүче КФҮгә шәхсән, телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Республика порталында, Республика порталында консультация алырга хокуклы.

КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә, шул исәптән тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен башка мәсьәләләр буенча консультацияләр бирә.

Гариза бирүче муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны ирекле файдалану юлы белән КФҮ сайтыннан http://mfc16.tatarstan.ru алырга мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгате көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

3.2.3. Гариза бирүче Башкарма комитетка телефон һәм электрон почта аша мөрәҗәгать итәргә, шулай ук муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Башкарма комитет сайтында консультация алырга хокуклы.

Консультация бирү өчен җаваплы вазыйфаи зат Регламентның 1.3.4 пункты таләпләре нигезендә гариза бирүчегә хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: тапшырыла торган документлар составы, формасы һәм муниципаль хезмәттән файдалану өчен кирәкле башка мәсьәләләр буенча консультацияләр.

### 3.3. Гариза бирүче тарафыннан тапшырылган документлар комплектын кабул итү һәм карап тикшерү

3.3.1. КФҮ яки КФҮнең читтәге эш урыны аша муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.1.1. Гариза бирүче (гариза бирүченең вәкиле) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запрос белән КФҮгә шәхсән мөрәҗәгать итә һәм Регламентның 2.5 пункты нигезендә документлар тапшыра.

3.3.1.2. КФҮнең гаризалар кабул итүче хезмәткәре:

мөрәҗәгать предметын билгели;

документлар бирүче затның вәкаләтләрен тикшерә;

документларның Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

КФҮ АМСда гаризаның электрон формасын тутыра;

Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән документлар кәгазьдә тапшырылганда, тапшырылган документларны сканерлауны гамәлгә ашыра;

КФҮ АМСдан гаризаны бастырып чыгара;

тикшерү һәм имзалау өчен гариза бирүчегә бирә;

имзаланганнан соң КФҮ АМСда имзаланган гаризаны сканерлый;

электрон формада тапшырылган документларны яки сканерланган документларның электрон рәвешләрен КФҮ АМСда йөкли, электрон дело формалаштыра;

имзаланган гаризаны һәм кәгазь документларның төп нөсхәләрен кире кайтара;

гариза бирүчегә документларны кабул итү турында расписка бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: җибәрү өчен әзер гариза һәм документлар пакеты.

3.3.1.3. КФҮ хезмәткәре гариза бирүчедән Башкарма комитетка электрон формада кабул ителгән документлар пакетын (электрон дело пакетлары составында) гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көннән башлап бер эш көне эчендә КФҮнең структур бүлекчәсенә җибәрә.

Процедураның нәтиҗәсе: электрон үзара хезмәттәшлек системасы аша Башкарма комитетка җибәрелгән гариза һәм документлар пакеты (электрон дело).

3.3.2. Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү өчен документлар кабул итү.

3.3.2.1. Гариза бирүче Республика порталы, Бердәм портал аша электрон формада гариза бирү өчен түбәндәге эшләрне башкара:

Республика порталында, Бердәм порталда авторизацияләүне башкара; Республика порталында, Бердәм порталда электрон гариза формасын ача; муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган мәгълүматларны үз эченә алган электрон гариза формасын тутыра;

электрон формадагы документларны яки документларның электрон рәвешләрен электрон гариза формасына беркетә (кирәк булганда);

электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле билге куя);

хәбәр ителгән мәгълүматларның дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле билге куя);

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза формасындагы тиешле төймәгә баса);

электрон гариза 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре һәм 210-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә (гади электрон имза һәм (яки) көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән) имзалана;

электрон гаризаны җибәрү турында белдерү кәгазе ала.

3.3.2.2. Формалаштырылган запросны формат-логик тикшерү, орган (оешма) билгеләгән таләпләр нигезендә, гариза бирүче тарафыннан запросның электрон формасының һәр кырын тутыру процессында, бердәм портал тарафыннан автомат рәвештә гамәлгә ашырыла. Бердәм портал, запросның электрон формасының дөрес тутырылмаган кырын ачыклаганда, турыдан-туры запросның электрон формасында мәгълүмати хәбәр аша, гариза бирүчегә ачыкланган хатаның характеры һәм аны бетерү тәртибе турында хәбәр ителәә.

Әлеге пункт белән билгеләнгән административ процедуралар гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: электрон хезмәттәшлек системасы аша Башкарма комитетка җибәрелгән электрон дело.

3.3.3. Башкарма комитет тарафыннан документлар комплектын кабул итү һәм карап тикшерү

3.3.3.1. Гариза һәм муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле башка документлар керү административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсе белгече (алга таба – документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

Документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, карап тикшерү өчен гариза һәм документлар кергәннән соң:

1) эшләр номенклатурасы нигезендә гаризага номеры һәм «Документларны тикшерү» статусы бирелә, бу исә Республика порталының, Бердәм порталның шәхси кабинетында чагылдырыла;

2) кергән электрон делоларны, шул исәптән гариза бирүче тарафыннан электрон формада теркәлгән документларны һәм документларның электрон рәвешләрен тикшерә;

3) документларның электрон рәвешләренең комплектлылыгын, укылуын тикшерә;

4) Бердәм порталга, Республика порталына мөрәҗәгать итү юлы белән, электрон имзаның чын булу шартлары үтәлешен тикшерә (гариза бирүче тарафыннан көчәйтелгән квалифицияле электрон имза белән имзаланган документларның электрон рәвешләре тапшырылган очракта).

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Көчәйтелгән квалификацияле электрон имзаны тикшерү нәтиҗәсендә аның чын булу шартлары үтәлмәү ачыкланган очракта, документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектында 63-ФЗ номерлы Федераль законның 11 статьясының аны кабул итү өчен нигез булган пунктлары булырга тиеш.

Баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты (муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр мондый документларга карата билгеләнгән таләпләрне бозу белән бәйле булган очракта, документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр тапшырылмаган, дөрес булмаган һәм (яки) каршылыклы мәгълүматларны үз эченә алган, билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән документларның (мәгълүматларның) исеме турында мәгълүматны үз эченә алырга тиеш), электрон документлар әйләнеше системасы аша билгеләнгән тәртиптә килештерү өчен җибәрелә.

Документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проектын килештерү Регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Регламентның 2.7.1 пунктында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, документлар кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат, гариза кергән көннән башлап бер эш көне эчендә, гаризада күрсәтелгән ысул белән, гариза бирүчегә гаризаның кергән теркәү номерын, гаризаны алу датасын, файл исемлекләренең, аңа тапшырылган документлар исемлеген, муниципаль хезмәт нәтиҗәсен алу датасын үз эченә алган гариза керү турында белдерү кәгазе җибәрә.

3.3.3.2. Регламентның 3.3.3.1 пунктында күрсәтелгән процедураларны башкару, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

3.3.3.3. Регламентның 3.3.3 пункты белән билгеләнә торган процедуралар карап тикшерү өчен гариза кергән көннән башлап бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәләре булып тора: карап тикшерү өчен кабул ителгән гариза яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту турында карар проекты.

### 3.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүдә катнашучы органнарга ведомствоара запрослар җибәрү

3.4.1. Административ процедураны башкаруга вәкаләтле вазыйфаи зат (хезмәткәр) тарафыннан документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи заттан (хезмәткәрдән)

гариза бирүчедән кабул ителгән документларны алу административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып АШТһТҮИ шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге белгече (алга таба – ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

Ведомствоара запросларны җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат, Регламентның 2.6 пунктында каралган документларны һәм мәгълүматларны тапшыру турында запросларны ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша (техник мөмкинлек булмаганда – башка ысуллар белән) электрон формада формалаштыра һәм җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар карап тикшерү өчен гариза кабул ителгән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: хакимият органнарына һәм (яки) хакимият органнарының ведомство буйсынуындагы оешмаларына җибәрелгән запрослар.

3.4.2. Мәгълүматлар белән тәэмин итүчеләрнең белгечләре, ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша кергән запрослар нигезендә, сорала торган документларны (мәгълүматны) бирәләр яки муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документ һәм (яки) мәгълүмат булмау турында белдерү кәгазьләре (алга таба – баш тарту турында белдерү кәгазе) җибәрәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, әгәр федераль законнарда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең хокукый актларында һәм федераль законнар нигезендә кабул ителгән Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында ведомствоара запроска җавап әзерләү һәм җибәрүнең башка сроклары билгеләнмәгән булса, документны һәм мәгълүматны бирүче органга яки оешмага ведомствоара запрос кергән көннән башлап өч көн эчендә гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) яисә ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән баш тарту турында белдерү кәгазе.

3.4.3. Ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

1) ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша сорала торган муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны (мәгълүматларны) яисә документ һәм (яки) мәгълүмат булмаганда баш тарту турында белдерү кәгазен ала;

2) Регламентның 2.7.1 пунктында каралган нигезләр булганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты, баш тарту сәбәпләрен (Регламентка 3 нче кушымта) күрсәтеп, Регламентның 3.5.3 пунктында каралган тәртиптә килештерү өчен җибәрелә.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) комплекты.

3.4.4. Регламентның 3.4.1, 3.4.3 пунктларында күрсәтелгән процедураларны башкару, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, шул исәптән Регламентның 2.13 пункты нигезендә гариза теркәлгән вакыттан башлап, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

3.4.5. Регламентның 3.4 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы өч эш көне тәшкил итә.

### 3.5. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү

3.5.1. Административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып,

ведомствоара запрослар җибәрү өчен җаваплы вазыйфаи заттан муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар (мәгълүматлар) комплекты керү тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат булып АШТһТҮИ шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге белгече (алга таба – муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

3.5.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

1) төзелешкә рөхсәт бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар булуны тикшерә;

2) проект документларының төзелешкә рөхсәт алу өчен бирелгән җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата таләпләргә, яки линия объекты төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, территорияне планлаштыру проекты һәм территорияне межалау проекты таләпләренә (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен территорияне планлаштыру буенча документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш), аны урнаштыру өчен җир участогы булдыру таләп ителми торган линия объекты төзелешенә рөхсәт биргән очракта, территорияне планлаштыру проектында билгеләнгән таләпләргә туры килүен, шулай ук капиталь төзелеш объектының урнашуы җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм Россия Федерациясенең җир һәм башка законнары нигезендә билгеләнгән чикләүләр нигезендә урнашуын рөхсәт ителүен тикшерә. Затка рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең иң чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирелгән очракта, проект документларының рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәттә билгеләнгән таләпләргә туры килүенә тикшерү үткәрелә;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләр ачыкланганда, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр булмаган очракта, Регламентның 2.3 пункты нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе проектын әзерли;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсенең әзерләнгән проектын билгеләнгән тәртиптә электрон документлар әйләнеше системасы аша килештерү өчен җибәрә.

Әзерләнгән һәм кимчелекләре булган карарлар проекты муниципаль хезмәт нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы затка кире кайтарыла.

Линия объекты булып тормаган һәм аны төзү яки реконструкцияләү федераль яки региональ әһәмияткә ия тарихи җирлек территориясе чикләрендә планлаштырыла торган капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт бирү турында гариза бирелгән һәм төзелешкә рөхсәт бирү турында гаризага РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 10.1 өлешендә күрсәтелгән бәяләмә теркәлмәгән яисә төзелешкә рөхсәт бирү турында гаризада аның нигезендә капиталь төзелеш объектын төзү яки реконструкцияләү планлаштырыла торган типовой архитектура карарына күрсәтмә булмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазифаи зат:

1) күрсәтелгән гаризаны алган көннән башлап өч көн эчендә, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазифаи зат төзелешкә рөхсәт бирү турында карар кабул итү өчен кирәкле документлар булуга тикшерү үткәрә һәм аңа теркәлгән капиталь төзелеш объектының архитектура карарларын үз эченә алган проект документлары өлешен Россия Федерациясе субъектының мәдәни мирас объектларын саклау өлкәсендә вәкаләтләнгән башкарма хакимият органына җибәрә;

2) проект документларының төзелешкә рөхсәт алу өчен тапшырылган җир участогының шәһәр төзелеше планын бирү датасына билгеләнгән капиталь төзелеш объектын төзүгә, реконструкцияләүгә карата таләпләргә туры килүенә, җир участогыннан рөхсәт ителгән файдалану һәм Россия Федерациясенең җир һәм башка

законнары нигезендә билгеләнгән һәм төзелешкә рөхсәт бирү датасына гамәлдә булган чикләүләр нигезендә капиталь төзелеш объектын урнаштыру мөмкинлегенә, шулай ук затка мондый рөхсәт бирелгән очракта, рөхсәт ителгән төзелешнең, реконструкциянең чик параметрларыннан тайпылуга карата билгеләнгән таләпләргә туры килүенә тикшерү үткәрә.

3.5.3. Төзелешкә рөхсәт бирү турында карар проектын килештерү һәм имзалау АШТһТҮИ шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге башлыгы, АШТһТҮИ башлыгы, АШТһТҮИ башлыгы урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын килештерү һәм имзалау АШТһТҮИ шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге башлыгы, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

3.5.4. Регламентның 3.5.2, 3.5.3 пунктларда күрсәтелгән процедураларны башкару, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

3.5.5. Регламентның 3.5 пунктында күрсәтелгән административ процедураларны башкаруның максималь срогы бер эш көне тәшкил итә.

Административ процедуралар, карап тикшерү өчен документлар пакеты муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен әзерләү өчен җаваплы вазыйфаи затка кергән вакыттан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Административ процедураларны башкару нәтиҗәсе булып тора: төзелешкә рөхсәт бирү турында карар проекты яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты.

3.6. Гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен бирү (җибәрү)

3.6.1. Административ процедураны башкара башлау өчен җаваплы вазыйфаи зат тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документны алу административ процедураны башкара башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат булып АШТһТҮИ белгече (алга таба – документларны бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

Документлар бирү (җибәрү) өчен җаваплы вазыйфаи зат:

муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында мәгълүматларны теркәүне һәм, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасы документларын алып бару системасына һәм (яки) шәһәр төзелеше эшчәнлеген тәэмин итү буенча мәгълүмат системасына кертүне тәэмин итә;

гариза бирүчегә (аның вәкиленә) электрон хезмәттәшлек юлы белән муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе турында һәм муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен КФҮдә алу мөмкинлеге турында Республика порталы, Бердәм портал аша хәбәр итә.

Процедураларны үтәү, техник мөмкинлек булганда, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен билгеләнгән автоматлаштырылган мәгълүмат системасыннан файдаланып, автомат режимда гамәлгә ашырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

3.6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен бирү (җибәрү) тәртибе:

3.6.2.1. Гариза бирүче муниципаль хезмәт нәтиҗәсен сорап КФҮгә мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә муниципаль хезмәт нәтиҗәсен электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе формасында бирә. Гариза бирүченең таләбе буенча, электрон документның кәгазьдәге нөсхәсе белән бергә, алынмалы йөрткечкә яздыру юлы белән, аңа электрон документ нөсхәсе бирелергә мөмкин.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар, КФҮнең эш регламентында билгеләнгән срокларда, гариза бирүче килгән көнне чират тәртибендә гамәлгә ашырыла.

3.6.2.2. Гариза бирүче Республика порталы, Бердәм портал аша муниципаль хезмәт күрсәтүне сорап мөрәҗәгать иткәндә, Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булган документның электрон рәвеше автомат рәвештә гариза бирүчегә җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Башкарма комитетның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне (күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ имзаланган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Республика порталыннан, Бердәм порталдан, КФҮдән файдаланып, гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтүне (шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тартуны) раслаучы документ җибәрү (бирү) яисә шәһәр Башкарма комитетында шәхсән имза куйдырып, турыдан-туры гариза бирүченең кулына тапшыру.

### 3.7. Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайтуга бәйле рәвештә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гаризаны карап тикшерү һәм төзелешкә рөхсәтне озайту турында яисә төзелешкә рөхсәтне озайтудан баш тарту турында карар кабул итү

3.7.1. Теркәлгән гариза һәм, документларны карап тикшерү өчен җаваплы вазыйфаи затны күрсәтеп, аңа теркәлгән документлар «Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайтуга бәйле рәвештә төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гаризаны карап тикшерү һәм төзелешкә рөхсәтне озайту турында яисә төзелешкә рөхсәтне озайтудан баш тарту турында карар кабул итү» административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып АШТһТҮИнең шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге белгече (алга таба – гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшерү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

3.7.2. Гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшерү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

а) гаризаның дөрес тутырылуын, әлеге Регламентның 2.5.2 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар булуын, аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

б) гаризаның һәм аңа теркәлгән документларның дәүләт хезмәте күрсәтүне регламентлаштыра торган норматив хокукый актлар таләпләренә туры килүен тикшерә;

в) Регламентның 3.7.2 пунктының а, б пунктчаларында күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәләре буенча, аның гамәлдә булу срогын озайтып, төзелешкә рөхсәт проектын яки төзелешкә рөхсәт срогын озайтудан баш тарту турында карар әзерли.

3.7.3. Гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшерү буенча гамәлләрне гамәлгә ашыру срогы – гаризаны теркәү көнен дә кертеп, 5 эш көне.

3.7.4. Административ процедура нәтиҗәсе булып, аның гамәлдә булу срогын озайтып, төзелешкә гамәлдәге рөхсәт яисә төзелешкә рөхсәт бирү срогын озайтудан баш тарту турында карар тора.

3.7.5. Гамәлдә булу срогы озайтылган төзелешкә рөхсәтне килештерү һәм имзалау Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Төзелешкә рөхсәтне озайтудан баш тарту турында карар проектын килештерү һәм имзалау АШТһТҮИнең шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге башлыгы, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайу сәбәпле, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

а) төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогын озайту зарурлыгына бәйле рәвештә, үзгәрешләр кертү турында гариза бирү көненә дәүләт төзелеш күзәтчелеге, дәүләт җир күзәтчелеге яки муниципаль җир контроле кысаларында төзелеш, реконструкция буенча башланган эшләр булмау факты турында мәгълүмат булу;

б) Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 52 статьясының 5 өлеше таләпләре нигезендә мондый хәбәр җибәрү мәҗбүри булып торса, төзелеш, реконструкция буенча эшләр башлану турында хәбәр булмау турында дәүләт төзелеш күзәтчелеге органының мәгълүматы булу;

в) төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гариза, төзелешкә рөхсәтнең гамәлдә булу срогы тәмамланганчы 10 эш көненнән ким вакыт эчендә бирелү.

### 3.8 Җир участогына хокуклар күчү сәбәпле, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гаризаны карап тикшерү

3.8.1 Теркәлгән гариза һәм, документларны карап тикшерү өчен җаваплы вазыйфаи затны күрсәтеп, аңа теркәлгән документлар «Җир участогына хокуклар күчү сәбәпле, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертү турында гаризаны карап тикшерү» административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

Административ процедураны башкару өчен җаваплы вазыйфаи зат (хезмәткәр) булып АШТһТҮИнең шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге белгече (алга таба – гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшерү өчен җаваплы вазыйфаи зат) тора.

3.8.2. Гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшерү өчен җаваплы вазыйфаи зат:

а) гаризаның дөрес тутырылуын, әлеге Регламентта каралган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар булуын, аларның билгеләнгән таләпләргә туры килүен тикшерә;

б) гаризаның һәм аңа теркәлгән документларның дәүләт хезмәте күрсәтүне регламентлаштыра торган норматив хокукый актлар таләпләренә туры килүен тикшерә;

в) Регламентның 3.8.2 пунктының а, б пунктчаларында күрсәтелгән процедураларның нәтиҗәләре буенча, кертелгән үзгәрешләре белән төзелешкә рөхсәт проектын яисә җир участогына хокуклар күчү сәбәпле төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар әзерли.

Гаризаны һәм аңа теркәлгән документларны карап тикшерү буенча гамәлләрне гамәлгә ашыру срогы – гаризаны теркәү көнен дә кертеп, 5 эш көне.

Административ процедураның нәтиҗәсе булып, җир участогының яңа хокук иясен күрсәтеп, төзелешкә яңа рөхсәт яисә җир участогына хокуклар күчү сәбәпле, төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, баш тарту турында карар тора.

Җир участогының яңа хокук иясен күрсәтеп, төзелешкә рөхсәтне килештерү һәм имзалау Башкарма комитет Җитәкчесе тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җир участогына хокуклар күчү сәбәпле төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар проектын килештерү һәм имзалау АШТһТҮИнең шәһәр төзелешен контрольдә тоту һәм рөхсәт бирү бүлеге башлыгы, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Җир участогына хокуклар күчү сәбәпле төзелешкә рөхсәткә үзгәрешләр кертүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

1) җир участогына хокуклар күчү турында белдерү кәгазендә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 21.13 өлешендә күрсәтелгән документларның реквизитлары булмау яисә РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясының 7 өлешендә каралган документлар булмау;

2) җир участогына хокуклар күчү турында белдерү кәгазендә күрсәтелгән мәгълүматлар дөрес булмау.

## 3.9. Техник хаталарны төзәтү

3.9.1. Муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Башкарма комитетка тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (4 нче кушымта);

гариза бирүчегә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе буларак бирелгән техник хаталы документ;

техник хата булуны раслаучы юридик көчкә ия документлар.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып торган документта күрсәтелгән мәгълүматлардагы техник хатаны төзәтү турында гариза, гариза бирүче (вәкаләтле вәкил) тарафыннан почта аша (шул исәптән электрон почтадан файдаланып) яисә Республика порталы, Бердәм портал яки КФҮ аша бирелә.

3.9.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи зат техник хатаны төзәтү турында гаризаны кабул итүне гамәлгә ашыра, теркәлгән документлары белән бергә гаризаны терки һәм документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган административ процедуралар гариза теркәлгән датадан башлап бер эш көне эчендә башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: кабул ителгән, теркәлгән һәм карап тикшерү өчен документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи затка җибәрелгән гариза.

3.9.3. Документларны эшкәртү өчен җаваплы вазыйфаи зат документларны карап тикшерә һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып торган документка төзәтмәләр кертү максатында, Регламентның 3.6 пунктында каралган процедураларны гамәлгә ашыра һәм төзәтелгән документны, имза куйдырып, шәхсән гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә, төп нөсхәсен гариза бирүчедән (вәкаләтле вәкилдән) алып, техник хата булган документны гариза бирүчегә (вәкаләтле вәкилгә) бирә яки техник хаталы документның төп нөсхәсен Башкарма комитетка тапшырганда документны алу мөмкинлеге турында хатны гариза бирүчегә почта аша (электрон почта аша) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан яисә теләсә кайсы кызыксынган заттан җибәрелгән хата турында гариза кергәннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

### 3.10. Гомуми билгеләре буенча, шул исәптән аны алу өчен мөрәҗәгать иткән муниципаль хезмәт нәтиҗәсенә мөнәсәбәтле рәвештә берләштерелгән гариза бирүчеләрнең аерым категорияләренә муниципаль хезмәт күрсәтү

Муниципаль хезмәт гариза бирүченең категориясенә һәм мөрәҗәгатьнең нигезенә бәйсез рәвештә күрсәтелә.

## 4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

### 4.1. Җаваплы вазыйфаи затлар тарафыннан Регламент нигезләмәләрен һәм муниципаль хезмәт күрсәтүгә таләпләрне билгели торган башка норматив хокукый актларны үтәүне һәм башкаруны, шулай ук алар тарафыннан карарлар кабул итүне агымдагы контрольдә тоту тәртибе

Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тоту гариза бирүчеләрнең хокукларын бозу очракларын ачыклау һәм бетерүне, муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлешенә тикшерүләр үткәрү, җирле үзидарә органы вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) карарлар әзерләүне үз эченә ала.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формалары булып түбәндәгеләр тора:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү буенча документ проектларын тикшерү һәм килештерү;

2) эш башкаруны алып баруга карата билгеләнгән тәртиптә үткәрелә торган тикшерүләр;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү процедураларының үтәлеше буенча билгеләнгән тәртиптә контроль тикшерүләр үткәрү.

Агымдагы контроль максатларында электрон мәгълүматлар базасында булган мәгълүматлар, хезмәт корреспонденциясе, административ процедураларны башкаруны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның телдән һәм язма мәгълүматы, тиешле документларны исәпкә алу журналлары һәм башка мәгълүматлар файдаланыла.

Муниципаль хезмәт күрсәткәндә һәм карарлар кабул иткәндә гамәлләр кылуга контрольне гамәлгә ашыру өчен Башкарма комитет Җитәкчесенә муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре турында мәгълүматлар бирелә.

Административ процедураларның срокларын, эзлеклелеген һәм эчтәлеген бозу очраклары һәм сәбәпләре турында вазыйфаи затлар кичекмәстән Башкарма комитет Җитәкчесенә хәбәр итәләр, шулай ук кимчелекләрне бетерү буенча ашыгыч чаралар күрәләр.

Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча административ процедураларда билгеләнгән гамәлләрнең эзлеклелеге үтәлешен агымдагы контрольдә тоту Башкарма комитет Җитәкчесенең муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эшне оештыру өчен җаваплы урынбасары, муниципаль хезмәт күрсәтү буенча эш оештыруны гамәлгә ашыручы АШТһТҮИ башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Агымдагы контрольне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның исемлеге җирле үзидарә органының структур бүлекчәләре турындагы нигезләмәләр һәм вазыйфаи регламентлар нигезендә билгеләнә.

### 4.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын планлы һәм планнан тыш тикшерүләрне гамәлгә ашыру тәртибе һәм вакыты, шул исәптән муниципаль хезмәт күрсәтү тулылыгын һәм сыйфатын контрольдә тотуның тәртибе һәм формалары

Контроль тикшерүләр планлы (җирле үзидарә органының ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә гамәлгә ашырылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин. Тикшерүләр үткәргәндә муниципаль хезмәт күрсәтү (комплексы тикшерүләр) белән бәйле, яки гариза бирүченең конкрет мөрәҗәгате буенча барлык мәсьәләләр каралырга мөмкин.

4.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның
вазыйфаи затларының муниципаль хезмәт күрсәтү барышында
кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары
һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен җаваплылыгы

Үткәрелгән тикшерүләрнең нәтиҗәләре буенча, гариза бирүчеләрнең хокукларын бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартылалар.

Башкарма комитет Җитәкчесе гариза бирүчеләрнең мөрәҗәгатьләре үз вакытында карап тикшерелмәү өчен җаваплы.

Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары һәм АШТһТҮИ башлыгы әлеге Регламентның 3 бүлегендә күрсәтелгән административ гамәлләрнең үз вакытында һәм (яки) тиешенчә үтәлмәве өчен җаваплы.

Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында кабул ителә (гамәлгә ашырыла) торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) өчен вазыйфаи затлар һәм башка муниципаль хезмәткәрләр законда билгеләнгән тәртиптә җаваплы.

4.4. Муниципаль хезмәт күрсәтүне, шул исәптән гражданнар, аларның
берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контрольдә тоту тәртибенә
һәм формаларына карата таләпләрне характерлаучы нигезләмәләр

Муниципаль хезмәт күрсәтүне гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалар ягыннан контрольдә тоту муниципаль хезмәт күрсәткәндә җирле үзидарә органы эшчәнлегенең ачыклыгы, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе һәм муниципаль хезмәт күрсәтү процессында мөрәҗәгатьләрне (шикаятьләрне) судка кадәр карап тикшерү мөмкинлеге турында тулы, актуаль һәм дөрес мәгълүмат алу аша гамәлгә ашырыла.

5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның,
КФҮнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының
1.1 өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның
вазыйфаи затларының, муниципаль хезмәткәрләренең, хезмәткәрләренең
карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына)
судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе

5.1. Муниципаль хезмәттән файдаланучылар муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәрнең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең, КФҮнең, күпфункцияле үзәк хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә шикаять бирергә хокуклы.

Гариза бирүче шикаять белән мөрәҗәгать итәргә мөмкин, шул исәптән түбәндәге очракларда:

1) муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросны, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 15.1 статьясында күрсәтелгән запросны теркәү срогын бозу;

2) муниципаль хезмәт күрсәтү срогын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче

тарафыннан күпфункцияле үзәкнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган КФҮгә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

3) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру яки гамәлгә ашыру каралмаган документлар яки мәгълүмат яисә эшләрне гамәлгә ашыруны таләп итү;

4) муниципаль хезмәт күрсәтү өчен гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) баш тарту өчен нигезләр федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта, муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган КФҮгә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

6) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган түләү таләп итү;

7) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның яки аларның хезмәткәрләренең муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә андый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозу. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган КФҮгә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

8) муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү срогын яки тәртибен бозу;

9) туктату нигезләре федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителгән Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда каралмаган очракта муниципаль хезмәт күрсәтүне туктату. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган КФҮгә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин;

10) муниципаль хезмәт күрсәткәндә гариза бирүчедән 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, муниципаль хезмәт күрсәтүдән яисә муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренче тапкыр баш тартканда булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгән документларны яки мәгълүматны таләп итү. Күрсәтелгән очракта гариза бирүче тарафыннан

КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең караларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.3 өлешендә билгеләнгән тәртиптә, карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган КФҮгә тулы күләмдә тиешле муниципаль хезмәт күрсәтү буенча функция йөкләнгән очракта мөмкин.

5.2. Шикаять язмача кәгазьдә, электрон формада муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, КФҮгә яисә КФҮне гамәлгә куючы булып торган тиешле дәүләт хакимияте органына (алга таба – күпфункцияле үзәкне гамәлгә куючы), шулай ук 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларга бирелә. Муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр югары органга (ул булганда) бирелә яисә ул булмаган очракта, турыдан-туры муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесе тарафыннан карала. КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге күпфункцияле үзәк җитәкчесенә бирелә. КФҮнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр КФҮне гамәлгә куючыга яки Татарстан Республикасының норматив хокукый акты белән вәкаләтләнгән вазыйфаи затка бирелә. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

Муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының, муниципаль хезмәткәренең, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган җитәкчесенең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, күпфункцияле үзәк аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, муниципаль хезмәт күрсәтүче органның рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан яисә Республика порталыннан, судка кадәр шикаять бирү буенча мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, күпфункцияле үзәкнең рәсми сайтыннан, Бердәм порталдан яисә Республика порталыннан, судка кадәр шикаять бирү буенча мәгълүмат системасыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин. 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять почта аша, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәреннән, әлеге оешмаларның рәсми сайтларыннан, Бердәм порталдан яисә Республика порталыннан файдаланып җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.3. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирелә торган муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) хезмәткәрләренең исеме;

2) гариза бирүченең – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турында мәгълүматлар яисә гариза бирүченең – юридик затның урнашу урыны турында мәгълүматлар, шулай ук элемтә өчен телефон номеры (номерлары), электрон почта адресы (булган очракта) һәм гариза бирүчегә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы;

3) муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның,

аларның хезмәткәрләренең шикаять белдерелә торган карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында мәгълүматлар;

4) гариза бирүченең муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган вазыйфаи затының яисә муниципаль хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның, аларның хезмәткәрләренең карарлары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән нинди нигездә килешмәвенең дәлилләре.

5.4. Кергән шикаять, кергән көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

5.5. Муниципаль хезмәт күрсәтүче органга, КФҮгә, КФҮне гамәлгә куючы органга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларга яисә югары органга (ул булганда) кергән шикаять, аны теркәгән көннән башлап унбиш эш көнендә, ә муниципаль хезмәт күрсәтүче органның, КФҮнең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә каралган оешмаларның гариза бирүчедән документларны кабул итүдән яисә җибәрелгән ялгышларны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуына шикаять бирелгән очракта яки мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуга шикаять бирелгән очракта – аны теркәгән көннән башлап биш эш көне эчендә карап тикшерелергә тиеш.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, хезмәт күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында, муниципаль хокукый актларда түләтү каралмаган акчаларны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә;

2) шикаятьне канәгатьләндерүдән баш тартыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килүче көннән дә соңга калмый, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүченең теләге буенча электрон формада шикаятьләрне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап җибәрелә.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында җавапта, муниципаль хезмәт күрсәткәндә ачыкланган кимчелекләрне тиз арада бетерү максатында, муниципаль хезмәт күрсәтүче орган, КФҮ яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясының 1.1 өлешендә күрсәтелгән оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук тудырылган уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә һәм муниципаль хезмәттән файдалану максатында гариза бирүче башкарырга тиешле алдагы гамәлләр турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип танылган очракта, гариза бирүчегә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында җавапта кабул ителгән карар сәбәпләре турында дәлилләнгән аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат бирелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар яки җинаять составы билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү вәкаләтләре бирелгән вазыйфаи зат, хезмәткәр булган материалларны кичекмәстән прокуратура органнарына җибәрә.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы — Н.И. Галиева

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына 1 нче кушымта

Кемгә ______________________________
(муниципаль берәмлекнең
______________________________
җирле үзидарә органы исеме)

кемнән: ______________________________
төзелеш, капиталь
______________________________
ремонт яки реконструкцияләүне планлаштыручы
______________________________
ИНН; юридик и почта адресы;
______________________________
җитәкченең Ф.И.А.и.; телефон;
______________________________
банк реквизитлары (банкның исеме, р/с, к/с, БИК)

Төзелешкә рөхсәт бирү турында
гариза

______________________________________________________________
(шәһәр, район, урам, участок номеры)

адресы буенча урнашкан җир участогында ____________ ай срокка ____________________
______________________________________________________________
(объектның исеме)

төзүгә/реконструкцияләүгә рөхсәт бирүне сорыйм.
(кирәклесенең астына сызарга)

Төзелеш (реконструкцияләү) _________елның «_____» __________ номерлы ___________________________________________документ нигезендә гамәлгә ашырылачак.

Җирдән файдалануга хокук ________елның «____» номерлы
______________________________________________________________
(документның исеме)

нигезендә беркетелгән.

Объектны төзүгә проект документлары проект документларын эшләүгә хокукы булган (документның һәм аны биргән оешманың исеме, бирү датасын һәм номерын күрсәтергә)
______________________________________________________________
______________________________________________________________
(проект оешмасының исеме, ИНН, юридик һәм почта адресы,
______________________________________________________________
җитәкченең Ф.И.А.и., телефон номеры, банк реквизитлары)

эшләнгән һәм түбәндәге кызыксынучы оешмалар һәм архитектура һәм шәһәр төзелеше органнары белән билгеләнгән тәртиптә килештерелгән:

дәүләт экспертизасының уңай бәяләмәсе № ______________
«_____» _________________ ел;

жир участогының планлаштыруны оештыру схемасы килештерелгән ____________________

____________________________________ № ____________ «_____» ____________ ел.

(оешманың исеме)

Проект-смета документлары расланган ________________________________________

____________________________________ № ____________ «_____» ____________ ел.

Өстәмә хәбәр итәбез:

Төзүче тарафыннан төзелешне финанслау (реконструкцияләү, капиталь ремонт) гамәлгә ашырылачак ____________________________________________________________

(банк реквизитлары һәм счет номеры)

Эшләр подряд (хуҗалык итү) ысулы белән

_____елның «_____» _________________ № ______________________________

шартнамә нигезендә ________________________________________________________

(оешманың исеме, ИНН,

________________________________________________________________________

юридик һәм почта адреслары, җитәкченең Ф.И.А.и., телефон номеры,

________________________________________________________________________

банк реквизитлары (банкның исеме, р/с, к/с, БИК))

алып барылачак.

Төзелеш-монтаж эшләрен башкару хокукы ________________________

________________________________________________________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле оешманың исеме)

________________________________________________________________________

«_____» _________________ ел № ______________________

теркәлде.

Төзелеш эшләрен башкаручы итеп _______елның «______» _______ номерлы приказ нигезендә, махсус белеме _____________ һәм төзелештә _____стажы булган

________________________________________________________________________

________________________(вазыйфасы, фамилия, исеме, атасының исеме)

билгеләнде.

Төзелеш контроле «____» ______________ № ______________________________

шартнамә нигезендә

________________________________________________________________________

(оешманың исеме, ИНН, юридик һәм почта адреслары
җитәкченең Ф.И.А.и., телефон номеры,
банк

________________________________________________________________________

реквизитлары (банкның исеме, р/с, к/с, БИК))

гамәлгә ашыралачак.

Заказчы (төзүче) функцияләрен башкару хокукы ___________________________

________________________________________________________________________

(документның һәм аны биргән вәкаләтле оешманың исеме)

№ _________________________ «_____» ______________________ ел

теркәлде.

Гаризага түбәндәге сканерланган документлар теркәлә:

1) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләре һәм РФ Шәһәр төзелеше кодексының 48 статьясының 15 өлеше нигезендә расланган проект документларындагы түбәндәге материаллар:

а) аңлатма язуы;

б) җир участогының шәһәр төзелеше планында күрсәтелгән мәгълүмат нигезендә башкарылган җир участогын планлаштыру схемасы, ә проект документларын линия объектларына карата әзерләгән очракта территорияне планлаштыру проекты нигезендә башкарылган күчерү полосасы проекты (линия объектын төзү, реконструкцияләү өчен документлар әзерләү таләп ителми торган очраклардан тыш);

в) архитектура һәм конструктив карарлар булган бүлекләр, шулай ук инвалидларның капиталь төзелеш объектына керә алуын тәэмин итүгә юнәлдерелгән карарлар һәм чаралар (сәламәтлек саклау, мәгариф, мәдәният, ял, спорт һәм социаль-мәдәни һәм коммуналь-көнкүреш билгеләнешендәге башка объектларга, транспорт, сәүдә, җәмәгать туклануы объектларына, эшлекле, административ, финанс, дини билгеләнештәге объектларга, торак фонды объектларына кагылышлы проект документларын әзерләгән очракта);

г) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты (капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү башка капиталь төзелеш объектларын төзү, реконструкцияләү өчен кирәк булган очракта капиталь төзелеш объектларын, аларның өлешләрен сүтү буенча эшләрне оештыру проектын да кертеп);

7) проект документларын әзерләүне гамәлгә ашыручы затлар әгъзалыгына нигезләнгән үз-үзен җайга салучы оешма әгъзасы булган зат тарафыннан бирелгән һәм әлеге зат тарафыннан әлеге Кодекс нигезендә проектның баш инженеры вазыйфасында архитектура-төзелеш проектын оештыру буенча җәлеп ителгән белгеч тарафыннан расланган проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау кәгазе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.8 өлеше нигезендә проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта;

8) башкарма хакимият органы яки проект документларына экспертиза үткәргән оешма тарафыннан проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау кәгазе, РФ Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясындагы 3.9 өлеше нигезендә эксперт барышында проект документларына үзгәрешләр кертелгән очракта;

4) рөхсәт ителгән төзелеш, реконструкцияләүнең чик параметрларыннан чыгуга рөхсәт (төзүчегә мондый рөхсәт РФ Шәһәр төзелеше Кодексының 40 статьясы нигезендә бирелгән очракта);

5) мондый объектны реконструкцияләгән очракта, капиталь төзелеш объектының барлык хокук ияләренең ризалыгы, күпфатирлы йортны реконструкцияләүнең РФ Шәһәр төзелеше кодексының 51 статьясындагы 7 өлешнең 6.2 пунктында күрсәтелгән очракларыннан тыш, блоклы төзелеш йортларының берсен реконструкцияләгән очракта, бер рәттә блоклы төзелештәге барлык йортларның хокук ияләренең ризалыгы;

6) реконструкцияләү дәүләт хакимияте органы (дәүләт органы) булып торучы дәүләт (муниципаль) заказчысы, «Росатом» атом энергиясе буенча дәүләт корпорациясе, «Роскосмос» космик эшчәнлек буенча дәүләт корпорациясе, дәүләт бюджеттан тыш фонд белән идарә итү органы яки җирле үзидарә органы тарафыннан хокук иясе булган, аңа карата күрсәтелгән орган гамәлгә куючы фунуцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган, дәүләт (муниципаль) унитар предприятиесе, дәүләт (муниципаль) бюджет яки автономияле учреждение булган дәүләт (муниципаль) милкендәге капиталь төзелеш объектында үткәрелгән очракта - мондый реконструкцияләү үткәрүгә, шул исәптән реконструкцияләүне гамәлгә ашырганда күрсәтелгән объектка китерелгән зыянны каплау шартларын һәм тәртибен билгели торган килешү;

7) күпфатирлы йортта биналарның һәм машина-урыннарның милекчеләренең гомуми җыелышы карары, ул күпфатирлы йортны реконструкцияләгән очракта торак законнары нигезендә кабул ителә, яки күпфатирлы йорттагы биналарның һәм машина-урыннарының барлык милекчеләренең ризалыгы, әгәр мондый реконструкция нәтиҗәсендә күпфатирлы йортта гомуми милек күләме кимесә;

8) мәдәни мирас объектларын саклау буенча эшләр башкарганда мондый объектның конструктив һәм башка ышанычлылык һәм куркынычсызлык характеристикаларна кагылса, мәдәни мирас объектлары турында Россия Федерациясе законнарында каралган документлар.

9) аны урнаштыру сәбәпле, Россия Федерациясе законнары нигезендә территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә тиешле капиталь төзелеш объектын төзегән очракта яки аның нәтиҗәсендә реконструкцияләгән объектка карата территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона билгеләнергә яки элек билгеләнгән территориядән файдалануның махсус шартлары булган зона үзгәрергә тиешле капиталь төзелеш объектын реконструкцияләгән очракта, территориядән файдалануның махсус шартлары булган зонаны билгеләү яки үзгәртү турында карар;

10) капиталь төзелеш объектларын төзүне, реконструкцияләүне җирле үзидарә органы тарафыннан территорияне комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә гамәлгә ашыру планлаштырылган очракта территорияне үстерү турында шартнамә күчермәсе (территорияне комплекслы үстерү турында карар Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты яисә муниципаль берәмлек тарафыннан мөстәкыйль тормышка ашырылган яки яисә мондый карар РФ Шәһәр төзелеше нигезендә билгеләнгән юридик зат яки Россия Федерациясе субъекты тарафыннан тормышка ашырылган очраклардан тыш).

Запрос булганда, документларның сканерланган төп нөсхәләрен бирергә йөкләмә алам.

Әлеге гаризада бирелгән мәгълүматлар белән бәйле барлык үзгәрешләр турында ________________________________________________ хәбәр итәргә йөкләмә алам.

(вәкаләтле органның исеме)

________________________ ____________ ____________________

(вазыйфа) (имза) (Ф.И.А.и.)

«___»____________ 20__ ел

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

# ТӨЗЕЛЕШКӘ РӨХСӘТ

_____ бит

| | |
|---|---|
| 1 бүлек. Төзелешкә рөхсәт реквизитлары | |
| 1.1. Төзелешкә рөхсәт датасы: | |
| 1.2. Төзелешкә рөхсәт номеры: | |
| 1.3. Орган (оешма) исеме: | |
| 1.4. Әлеге рөхсәтнең гамәлдә булу срогы: | |
| 1.5. Үзгәрешләр яки төзәтмәләр кертү датасы: | |
| 2 бүлек. Төзүче турында мәгълүмат | |
| 2.1. Физик зат яки шәхси эшмәкәр турында мәгълүматлар | |
| 2.1.1. Фамилиясе: | |
| 2.1.2. Исеме: | |
| 2.1.3. Атасының исеме: | |
| 2.1.4. ИНН: | |
| 2.1.5. ШЭ ОГРН | |
| 2.2. Юридик зат турында мәгълүматлар | |
| 2.2.1. Тулы исеме: | |
| 2.2.2. ИНН: | |
| 2.2.3. ОГРН: | |
| 3 бүлек. Капиталь төзелеш объекты турында мәгълүматалар | |
| 3.1. Проект документлары нигезендә капиталь төзелеш объектының (этапның) исеме: | |
| 3.2. Проект документлары нигезендә капиталь төзелеш объектына карата башкарыла торган эшләр төре: | |

| | |
|---|---|
| 3.3. Капиталь төзелеш объектының адресы (урнашу урыны) | |
| 3.3.1. Россия Федерациясе субъекты | |
| 3.3.2. Россия Федерациясе субъекты составында муниципаль район, муниципаль округ, шәһәр округы яки шәһәр эчендәге территория (федераль әһәмиятк ия шәһәрләр өчен), федераль территория: | |
| 3.3.3. Муниципаль район составындагы (муниципаль район өчен) яки шәһәр округының шәһәр эчендәге районы составында шәһәр яки авыл җирлеге (федераль территорияләрдә урнашкан биналардан, төзелмәләрдән, корылмалардан тыш): | |
| 3.3.4. Торак пунктның тибы һәм исеме: | |
| 3.3.5. Планлаштырылган структура элементының исеме: | |
| 3.3.6. Урам-юл челтәре элементының исеме | |
| 3.3.7. Бинаның (корылманың) тибы һәм номеры: | |
| 4 бүлек. 2. Җир участогы турында мәгълүмат | |
| 4.1. Чикләрендә капиталь төзелеш объекты урнашкан яки урнаштыру планлаштырыла торган җир участогының (җир участокларының) кадастр номеры: | |
| 4.2. Чикләрендә капиталь төзелеш объекты урнашкан яки урнаштыру планлаштырыла торган җир участогының (җир участокларының) мәйданы: | |
| 4.3. Җир участогының шәһәр төзелеше планы турында мәгълүматлар | |
| 4.3.X.1. Дата: | |
| 4.3.X.2. Номеры: | |
| 4.3.X.3. Җир участогының шәһәр төзелеше планын бирген орган исеме: | |
| 4.4. Территориянең кадастр планында җир участогын яки җир участокларын урнаштыруның расланган схемасында җир участогының (җир участокларының) шартлы номеры (кирәк булганда): | |

| | |
|---|---|
| 4.5. Территориянең кадастр планында җир участогын яки җир участокларын урнаштыру схемасы турында мәгълүмат | |
| 4.5.1. Карар датасы: | |
| 4.5.2. Карар номеры: | |
| 4.5.3. Җир участогын яки җир участокларын урнаштыру схемасын раслау турында карар кабул иткән оешманың, вәкаләтле органның яки затның исеме: | |
| 4.6. Территорияне планлаштыру документлары турында мәгълүмат | |
| 4.6.1. Территорияне планлаштыру проекты турында мәгълүматлар | |
| 4.6.1.Х.1. Карар датасы: | |
| 4.6.1.Х.2. Карар номеры: | |
| 4.6.1.Х.3. Территорияне планлаштыру проектын раслау турында карар кабул иткән оешманың, вәкаләтле органның яки затның исеме: | |
| 4.6.2. Территорияне межалау проекты турында мәгълүматлар | |
| 4.6.2.Х.1. Карар датасы: | |
| 4.6.2.Х.2. Карар номеры: | |
| 4.6.2.Х.3. Территорияне межалау проектын раслау турында карар кабул иткән оешманың, вәкаләтле органның яки затның исеме: | |
| 5 бүлек. Проект документлары, типовой архитектура карары турында мәгълүматлар | |
| 5.1. Эшләүче - шәхси эшмәкәр турында мәгълүматлар | |
| 5.1.1. Фамилиясе: | |
| 5.1.2. Исеме: | |
| 5.1.3. Атасының исеме: | |
| 5.1.4. ИНН: | |
| 5.1.5. ШЭ ОГРН | |
| 5.2. Эшләүче - юридик зат турында мәгълүматлар | |
| 5.2.1. Тулы исеме: | |
| 5.2.2. ИНН: | |
| 5.2.3. ОГРН: | |

| | |
|---|---|
| 5.3. Раслау датасы (булганда): | |
| 5.4. Номер (булганда): | |
| 5.5. Тарихи җирлек өчен расланган капиталь төзелеш объектының типовой архитектура карары (булганда) | |
| 5.5.1. Дата: | |
| 5.5.2. Номеры: | |
| 5.5.3. Документның исеме: | |
| 5.5.4. Типовой архитектура карарын раслау турында карар кабул иткән вәкаләтле орган исеме: | |
| 6 бүлек. Проект документларына экспертиза һәм дәүләт экология экспертизасы нәтиҗәләре турында мәгълүмат | |
| 6.1. Проект документларына экспертиза турында мгълүматлар | |
| 6.1.Х.1. Раслау датасы: | |
| 6.1.Х.2. Номеры: | |
| 6.1.Х.3. Проект документларына экспертизаның уңай бәяләмәсен биргән органның яки оешманың исеме: | |
| 6.2. Дәүләт экология экспертизасы турында мәгълүматлар | |
| 6.2.Х.1. Раслау датасы: | |
| 6.2.Х.2. Номеры: | |
| 6.2.Х.3. Дәүләт экология экспертизасының уңай бәяләмәсен раслаган орган исеме: | |
| 6.3. Проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 3.8 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау | |
| 6.3.1. Дата: | |
| 6.3.2. Номеры: | |
| 6.3.3. Күрсәтелгән раслауны раслаган зат турында мәгълүматлар: | |
| 6.4. Проект документларына кертелә торган үзгәрешләрнең Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясының 3.9 өлешендә күрсәтелгән таләпләргә туры килүен раслау | |
| 6.4.1. Дата: | |
| 6.4.2. Номеры: | |

| | |
|---|---|
| 6.4.3. Туры килүгә бәяләүне үткәргән башкарма хакимият органының яки оешманың исеме: | |
| 7 бүлек. Капиталь төзелеш объектының проект характеристикалары | |
| 7.Х. Проект документларында каралган капиталь төзелеш объектының исеме: | |
| 7.Х.1. Капиталь төзелеш объектының төре: | |
| 7.Х.2. Объектның билгеләнеше: | |
| 7.Х.3. Реконструкциялнә торган капиталь төзелеш объектының кадастр номеры: | |
| 7.Х.4. Төзелеш мәйданы (кв.м): | |
| 7.Х.4.1. Капиталь төзелеш объектының бер өлеше төзелеше мәйданы (кв.м): | |
| 7.Х.5. Мәйданы (кв.м): | |
| 7.Х.5.1. Капиталь төзелеш объекты өлешенең мәйданы (кв.м): | |
| 7.Х.6. Торак булмаган бүлмәләрнең мәйданы (кв.м): | |
| 7.Х.7. Торак бүлмәләрнең мәйданы (кв.м): | |
| 7.Х.8. Бүлмәләр саны (штук): | |
| 7.Х.9. Торак булмаган бүлмәләр саны (данә): | |
| 7.Х.10. Торак бүлмәләр саны (данә): | |
| 7.Х.11. шул исәптән фатирлар (данә): | |
| 7.Х.12. Машина урыннары саны (данә): | |
| 7.Х.13. Этажлар саны: | |
| 7.Х.14. шул исәптән җир асты этажлары саны: | |
| 7.Х.15. Сыйдырышлыгы (кеше): | |
| 7.Х.16. Биеклеге (м): | |
| 7.Х.17. Башка күрсәткечләр: | |
| 8 бүлек. Линия объектының проект характеристикалары | |
| 8.Х. Проект документларында каралган линия объектының исеме: | |
| 8.Х.1. Реконструкцияләнә торган линия объектының кадастр номеры: | |

| | |
|---|---|
| 8.X.2. Озынлыгы (м): | |
| 8.X.2.1. Линия объектының яки өлешенең озынлыгы (м): | |
| 8.X.3. Категория (класс): | |
| 8.X.4. Егәрлеге (үткәрү сәләте, йөк әйләнеше, хәрәкәтнең интенсивлыгы): | |
| 8.X.5. Электр тапшыру линияләренең тибы (электр тапшыручы кабель линиясе, электр тапшыручы һава линиясе, электр тапшыручы кабель-һава линиясе), көчәнеш дәрәҗәсе: | |
| 8.X.6. Башка күрсәткечләр: | |

| | | |
|---|---|---|
| | | |
| төзелешкә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы органның (оешманың) вәкаләтле заты вазыйфасы | имза | инициаллар, фамилия |

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту турында
белдерү кәгазе

______________________________________________ мөрәҗәгать итү сәбәпле
(гариза бирүченең – физик затның Ф.И.А.и., юридик затның исеме)

гариза № _______ _____._____.________ел, ______________________________ турында

______________________________________________________________
______________________________________________________ нигезендә

тапшырылган документларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча, түбәндәге сәбәпләр нигезендә төзелешкә рөхсәт бирүдән баш тарту турында карар кабул ителде:

1.

2.

Вазыйфаи зат (Ф.И.А.и.)

_________________________
(килештерүне гамәлгә ашыра торган
орган вазыйфаи затының имзасы)

Башкаручы (Ф.И.А.и.)

______________________________
(башкаручы белән элемтә)

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
4 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә
кемнән:
______________________________

Техник хатаны төзәтү турында
гариза

________________________________________________________________
(хезмәтнең исеме)
муниципаль хезмәт күрсәткәндә җибәрелгән хата турында хәбәр итәм.

Язылган: ______________________________________________________
________________________________________________________________

Дөрес мәгълүматлар: ____________________________________________
________________________________________________________________

Җибәрелгән техник хатаны төзәтүне һәм муниципаль хезмәт нәтиҗәсе булып саналган документка тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Түбәндәге документларны терким:

1.
2.
3.

Техник хатаны төзәтү турындагы гаризаны кире кагу хакында карар кабул ителгән очракта, андый карарны түбәндәгечә җибәрүне сорыйм:

электрон документны E-mail: _____________________ адресына җибәрү юлы белән;

кәгазьдә расланган күчермә рәвешендә почта аша түбәндәге адреска җибәрүне:
_____________________________________________________________.

Моның белән раслыйм: әлеге гаризага теркәлгән, минем шәхескә һәм минем тарафтан күрсәтелгән затка кагыла торган, шулай ук түбәндә минем тарафтан кертелгән мәгълүматлар дөрес. Гаризага теркәлгән документлар (документларның күчермәләре) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән таләпләргә туры килә, гаризаны тапшыру вакытына бу документлар гамәлдә һәм төгәл мәгълүматларны үз эченә ала.

_______________ (дата) ___________________ (имза) ( __________________ ) (Ф.И.А.и.)

Төзелешкә рөхсәт бирү буенча
муниципаль хезмәт күрсәтүнең
административ регламентына
5 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре
Башкарма комитеты
Җитәкчесенә

___________________________________
(Ф.И.А.и.)

кемнән ______________________________________
(оешманың, предприятиенең исеме)

______________________________________________
(почта адресы, тел.)

______________________________________________
исәп-хисап счеты ___________________________

______________________________________________
кор счеты ___________________________________
БИК _______________________________________

ИНН _______________________________________

Тел: _______________________________________

Җир участогына хокуклар,
җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчү,
җир участогы булдыру турында белдерү кәгазе

Җир участогына хокуклар, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы күчү, җир участогы булдыру сәбәпле (*кирәк түгелен сызарга*), Сезгә, кадастр номеры _____________ булган, ______________________________________________________ адресы буенча
(җир участогы урнашу урынының тулы адресын яки башка тасвирламасын күрсәтергә)

урнашкан, аңа карата _______ елның «___» ____________ № ______ төзелешкә рөхсәт бирелгән җир участогы

_____________________________________________________________________________,
__________________________________________________________________ хокукында,
______________________________________________________________________ карый
(җир участогына хокук иясенең – гражданның тулы Ф.И.А.и һәм (яки) юридик затның исемен күрсәтергә)

һәм __________________________________________________________________________
(төзелешкә бирелгән рөхсәт нигезендә капиталь төзелеш объектының тулы исемен күрсәтергә)

капиталь төзелеш объектын төзү / реконструкцияләү *(кирәк түгелен сызарга)* өчен,

_______________________________________________________________________________
(төзелешкә рөхсәт биргән органның исемен күрсәтергә)

тарафыннан бирелгән _______ елның «___» ____________ № ______ төзелешкә рөхсәткә тиешле үзгәрешләр кертүне сорыйм.

Раслый торган документларның реквизитларын хәбәр итәм:

1) җир участогына хокук билгеләүче документлар ________________________________
________________________________________________________________________;

2) җир участоклары булдыру турында карар № ___ «___» ______________ ел,
____________________________________________________ тарафыннан кабул ителгән;
(дәүләт хакимияте башкарма органының яки җирле үзидарә органының исеме)

3) җир участокларын бүлү, яңадан бүлү яки җир участокларыннан аерып бирү юлы белән барлыкка килгән җир участогының шәһәр төзелеше планы № ___ «___» ______________ ел,
________________________________________________________ тарафыннан бирелгән
(төзелешкә рөхсәт биргән органның исемен күрсәтергә)

4) җир асты байлыкларыннан файдалану хокукы бирү турында карар № ___ «___» ______________ ел,
____________________________________________________ тарафыннан кабул ителгән;
(дәүләт хакимияте органының исеме)

һәм җир асты байлыкларыннан файдалануга лицензияне яңадан рәсмиләштергән очракта, җир асты байлыкларыннан файдалану хокукына лицензияне яңадан рәсмиләштерү турында карар № ___ «___» ______________ ел.

Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе, турыдан-туры шәхсән мөрәҗәгать иткәндә минем тарафтан кәгазь документ рәвешендә алынырга / почта аша минем адреска җибәрелергә / электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрелергә мөмкин *(тәкъдим ителгән ысулларның берсенең астына сызарга).*

Мин, гариза бирүче – физик зат, муниципаль хезмәттән файдалану максатында, персональ мәгълүматлар субъекты – минем тарафтан минем персональ мәгълүматларны бирү турында карар кабул ителергә һәм, җирле үзидарә органында расланган персональ мәгълүматларны эшкәртүгә ризалыкның типовой формасын тутыру юлы белән язма рәвештә, аларны эшкәртүгә ризалык бирелергә тиешлеге турында белдерелде, яисә, киресенчә булганда, миңа персональ мәгълүматларымны бирүдән баш тартуның юридик нәтиҗәләре турында аңлатылачак.

Гаризага түбәндәге документлар теркәлә:

1) ________________________________________________________________________;
2) ________________________________________________________________________;
3) ________________________________________________________________________;
4) ________________________________________________________________________;
5) ________________________________________________________________________.

Гариза бирүче ______________________________________________ ____________________
Гариза бирүченең / гариза бирүче вәкилегенең Ф.И.А.и.) (имза)

Дата ____ ________________20 _____.

Белгеч ______________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, имза)

Дата ____ ________________20 _____.